КИМ ТҮГЕЛ

Татарстанда шикәр чөгендере уңышы өметләрне аклаганмы?

> 2



КӨЗЕН ЧҮТЛЫЙСЫ

Быел Татарстан халкына 9,1 миллиард сум күләмендә милек салымы салганнар

> 2

КҮҢЕЛ ЭШЕ

«Татнефть» компаниясе үзе эшли торган төбәкләрдән килгән волонтерларны бергә җыйды

> 7

ҮЗГӘРҮ

«ВТ»ның Татарстанда яшәүче милләтләр турында махсус проекты

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 168 (29135) | Чәршәмбе | 15 ноябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

КАЛФАК ЧИГЕП КЕНӘ ТЕЛ САКЛАНМЫЙ

Борчыган мәсьәлә

«Күпләрне күргән башыңны
Инде син күтәр бераз».

Казанда узган I Бөтенроссия туган тел укытучылары форумының пленар утырышында Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин үз чыгышын Хәсән Туфанның әнә шул шигырь юллары белән башлады. Безне алда ни көтә? Фәнни-техник үсеш заманында туган телебезнең абруен саклап калу өчен ниләр эшләргә кирәк? Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашында узган чарада тәрбия, белем, тел мәсьәләләре турында сөйләштеләр.

tatarstan.ru

Россиянең 30 төбәгендә яшәүче 800гә якын туган тел укытучысы, иҗтимагый, мәдәни оешма, милли хәрәкәт вәкилләре Казанга өч көнлек форумга җыелды. Беренче көнне алар татар телендә белем бирүче алдынгы мәктәпләр тәҗрибәсе, яңа технологияләр белән танышты. Чарада татар теле укытучысының «өстәл китабы» да тәкъдим ителде. Анда укытучыга белем һәм тәрбия эшендә кирәкле норматив хокукый документлар, тел һәм мәдәният өлкәсенә кагылышлы грантлар, татар иҗтимагый оешма һәм автономияләре турында мәгълүматлар тупланган. Монысы юлны табар өчен кирәк.

Август аенда Бөтенроссия туган (татар) тел һәм әдәбияты укытучылары ассоциациясе төзелү дә – зур вакыйга. Берләшмә туган телләрне укытуга бәйле вазгыятькә анализ ясауны, грантларны тормышка ашыруны, шул ук вакытта укытучыларны яклауны да күздә тота. Бүген анда ил буенча 4 мең татар теле укытучысы теркәлгән. Оешма рәисе Рузилә Фәттахова чарада Татарстан районнарында, Россия төбәкләрендә ассоциациянең җирле бүлекләрен булдыру тәкъдиме белән чыкты. Ә менә туган телне саклауны татар теле укытучысына гына йөкләп калдыруны зур хата дип бәяләде.

Бөтендөнья татар конгрессы Милли шура рәисе Васыйл Шәйхразыев татар теле укытучыларын милләт сакчылары дип атады:

– Милләтне тәрбияләү һәм ана телен саклау барыбыздан да тора. Әти-әни, мәгариф оешмалары, мәдәни үзәкләр һәм башка дини, иҗтимагый оешмалар бергәләшеп эшләгәндә генә нәтиҗәгә ирешеп була.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов мондый җыеннарның әһәмиятенә басым ясады.

– Татар милләтен бөтен дөньяда белергә тиешләр, – диде Рәис. – Шушы юнәлештә барырга кирәк. Мондый очрашулар безгә кирәк, алар бик файдалы. Күргәзмә белән танышканнан соң, татар теленең, татар мәдәниятенең киләчәге зур дигән ышаныч бар. Бу юнәлештә зур эш алып барыла, төрле проектлар тормышка ашырыла һәм конкрет уңай нәтиҗәләр бар. Алга таба да актив эшләргә кирәк. Туган телебезне саклап калу бик мөһим. Монда гаилә, балалар бакчасы, мәктәп зур роль уйный. Һәм, әлбәттә, мөһим урынны нәкъ менә укытучы алып тора.

Илсур Һадиуллин баланың туган телне камил белмәвен дә ата-анага гына аударып калдыруның дөрес булмавын әйтте.

– Без бер-беребезне гаепләп, туган телдә тәрбия һәм укыту мәсьәләсен катлауландырабыз. Балалар бакчасы әти-әниләргә төртеп күрсәтә, мәктәп укытучысы тәрбиячегә ишарә ясый. Бу очракта «гаилә – балалар бакчасы – мәктәп» эш формуласы бербөтен һәм бердәм эшчәнлекне тәшкил итәргә тиеш, – диде министр.

Илсур Һадиуллин тагын бер мәртәбә туган телнең ата-ана гаризасы буенча укытылуын искә төшерде. «Беренчедән, безгә туган телне өйрәнү өчен конкрет хокукый механизм бирелде. Икенчедән, «Ата-ананың туган телен аңлы рәвештә сайлавы милли үзаң күрсәткече, «милли маркер» түгелме соң?» дигән сорау туа. Милләтпәрвәр дип күкрәк кагасың икән, рәхим итеп гаризаңны яз, туган телеңне сайла, өйрән!» – диде республиканың баш педагогы.

Министр ана-аналарны туган телне өйрәнүгә үгетләү өчен яхшы дәлил дә китерде. Галимнәрнең тикшеренү нәтиҗәләренә караганда, берничә телне белгән кешеләрнең баш мие яхшырак эшли. Бер телдән икенче телгә күчү фикерләү дәрәҗәсен яңа баскычка күтәрә.

Казандагы 13 нче гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, «Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы» бөтенроссия конкурсы җиңүчеләре бишлегенә кергән Алинә Шәгәрәева фикеренчә, бүген туган телгә бәйле күп кенә чаралар еш кына милли кием кию, калфак чигү һәм бишек яки сандык күрсәтүгә кайтып кала. Әлбәттә, аларны да белү кирәк. Төп бурыч – укучыларда тиз үзгәрүчән дөнья шартларында уңышлы яшәү һәм эшләү өчен кирәк булган күнекмәләр формалаштыру. Ул туган тел укытучыларын оптимист булырга чакырды. Татар телен югары дәрәҗәдә укыту өчен барлык шартлар булуын, мескенләнеп утырырга кирәкмәвен әйтте.

Читтә яшәүче башка милләт вәкилләре туган телебезне хөрмәт итеп кенә калмый, аны үз милләттәшләренә дә өйрәтә. Мәсәлән, татар теленнән халыкара олимпиадада Гран-при откан япон егете Юто Хишияма белән аның якташы Мидзуки Накамура. Алар, форум делегатларына видеосәламнәрен җиткереп, японнар өчен булдырылган татар теле дәреслеге һәм курслары турында сөйләде. Милләттәшләре бик яратып кабул иткән. Чарада чыгыш ясаган төрек кызы Гамзә Нур Налбантның да теләге чынга ашкан. Хәзер ул – Казан федераль университеты аспиранты.

Ахыры 2 нче биттә >

Пенсия арта

Дәүләт Думасы киләсе елда эшләмәүче пенсионерларга пенсия күләмен арттыру турында закон кабул иткән. Дума сайтындагы хәбәргә караганда, 2024 елның 1 гыйнварыннан картлык буенча иминият пенсиясе 7,5 процентка үсәчәк. Бу яңалык барлыгы 32 миллионнан артыграк кешегә кагылачак.

Дума Рәисе Вячеслав Володин әйтүенчә, моның өчен кирәкле барлык акча федераль бюджет проектына салынган. 2024 елда пенсияләрне индексацияләүгә чама белән 234 миллиард сум тотылачак.

Быел исә 1 гыйнвардан эшләмәүчеләргә иминият пенсиясе 4,8 процентка арттырылган. Хәзер пенсиянең уртача күләме 21864 сум тәшкил итә. Киләсе елда ул 22605 сумга җитәчәк.

Берләшү

Татарстанда кайбер фәнни оешмаларны Татарстан Фәннәр академиясенә кушачаклар. Шулай итеп, Мәрҗани исемендәге институт, Перспективалы икътисадый тикшеренүләр үзәге һәм Тормыш иминлеге фәнни үзәге академиянең аерым бүлекләренә әйләнәчәк. Премьер-министр Алексей Песошин дәүләт бюджет оешмаларын Фәннәр академиясенә кушу турында Министрлар Кабинеты карарын имзалаган. Документ фәнни тикшеренүләр мөмкинлекләрен үстерү, шулай ук республиканың дәүләт мөлкәтеннән нәтиҗәлерәк файдалану максатында кабул ителгән.

Фәнни учреждениеләрне үзгәртеп оештыруга 90 көн вакыт бирелә. Карарның үтәлешен контрольдә тоту Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем һәм фән бүлегенә йөкләнгән.

Дүрт җиңү!

Казан һәм республиканың тагын 3 муниципалитеты «Иң яхшы муниципалитет» бөтенроссия бәйгесендә җиңгән. Бәйгегә Премьер-министр Михаил Мишустин йомгак ясаган. Шулай итеп, Татарстан һәм Башкортстаннан – дүртәр, Чечня һәм Самара өлкәсеннән икешәр муниципалитет җиңү яулаган.

Казан, «Муниципаль икътисадый сәясәт һәм финанслар белән идарә итү» номинациясендә өченче урын яулап, 25,5 миллион сум откан. Менделеевск районының Татар Чаллысы авыл җирлеге «Муниципаль берәмлектә яшәүчеләр белән нәтиҗәле кире элемтә, җирле иҗтимагый үзидарәне үстерү» номинациясендә икенче урынга чыккан. Аңа 12,75 миллион сум юлланачак.

Моннан тыш Иннополис – «Цифрлы технологияләр нигезендә шәһәр хуҗалыгын модернизацияләү» номинациясендә, Биектау авыл җирлеге «Шәһәр төзелеше сәясәте, халыкның тормышы өчен уңай мохит тудыру һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү» номинациясендә өченче урын алган.

Сәламәтлек

Баллы түгел, мәкерле

Дөньяда яшәүче һәр ун кешенең берсе шикәр чиреннән интегә. Татарстанда исә 113 мең кеше исәптә тора. Аларның саны ел саен уртача 7 меңгә арта бара, дип чаң суга белгечләр. Бөтендөнья шикәр чиренә каршы көрәш көне алдыннан Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш эндокринологы Гөлнара Ваһапова журналистларга шундый саннар җиткерде.

Белгеч сүзләренә караганда, шикәр чире белән авыручылар саны зур тизлектә арта. Алар хәтта фаразланган күрсәткечләрне дә узып бара.

– 2011 елда тагын 20 елдан дөньяда шикәр чире белән авыручылар саны 550 миллионнан артып китәчәк дип фаразланган иде. Әмма бу фаразлар ун ел узгач ук чынга ашты. 2030 елга дөнья күләмендә аларның саны 600 миллионнан артыр дип фаразлана. 2045 елга исә бу чир 700 миллион кешедә ачыкланыр дип көтелә. Коточкыч саннар һәм фаразлар бу, – ди Гөлнара Ваһапова.

Шикәр чире үлем-китемгә китергән иң төп авыруларның берсе булып кала бирә. Рәсми саннардан күренгәнчә, Россиядә көн саен 300ләп кеше шушы авырудан үлә. Үз артыннан бик күп башка чирләрне дә ияртергә сәләтле мәкерле авыру бу. Ник дигәндә, шикәр чире еш кына кешенең йөрәк-кан тамырларына, күзенә, табанына бәрә. Казан (Идел буе) федераль университетының хирургия авырулары кафедрасы профессоры Александр Максимов сүзләренә караганда, соңгысы әлеге диагнозлы кешеләр арасында аеруча еш очрый.

– Шикәр чире аркасында табаны зарарланган кешенең атлап йөреше үзгәрә. Ул аякларын тоймый, хәтта аяк киеме кырса да, авыртуны сизми башлый. Вакытында дәваламасаң, табанда гангрена башланып, кешенең аягын кисәргә мөмкиннәр. Ул исә үлем ихтималын бермә-бер арттыра, – ди белгеч.

Шуңа күрә шикәр чиреннән интеккән кешеләргә уңайлы аяк киеменнән йөрергә, аяклардагы кан йөрешен даими рәвештә тикшертеп торырга киңәш итә ул. Аяк тырнакларын кискәндә дә сак булырга кирәк.

– Шикәр чире белән авыручылар беркайчан да уяулыкны югалтмасын иде. Юкса соңгы тапкыр авырулар арасында уздырган сораштыру нәтиҗәләре шаккатарлык. Шикәр чирле кешеләрнең күбесе, хәтта аягында гангрена ачыклангач та, табибка уртача 2,5 ай вакыт узгач кына мөрәҗәгать итә икән, – ди Александр Максимов.

Мәкерле чирне кисәтү өчен, дөрес тукланырга, гел хәрәкәттә булырга, вакытына диспансеризация узып торырга кирәклеген дә искәртте ул. «Чир никадәр иртәрәк табылса, аңа каршы көрәшү дә шулкадәр нәтиҗәлерәк», – ди белгеч.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

Александр ДВОЙНЫХ, Федерация Советының Аграр азык-төлек сәясәте һәм табигатьтән файдалану комитеты җитәкчесе:

Эре сәүдә челтәрләрендә фермер товарларын сату өчен агроагрегаторлар урнаштырырга кирәк. Беренче чиратта без авыл кешеләренең акча эшләү механизмнарын булдырырга тиеш. Төп проблема – фермер продукциясен сату формасы.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – ЮЛЛАР

РОССИЯДӘ ЮЛ ОЗЫНЛЫГЫ (мең км)

2007 ел >> **747** ● 2022 ел >> **1576**

1008 >> җирле әһәмияттәге юллар
503 >> төбәк һәм муниципаль әһәмияттәге юллар
64 >> федераль әһәмияттәге юллар

**Росстат мәгълүматлары буенча*

Сыйлы һәм сыйсызлар

Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында агымдагы елның 10 ае буенча терлекчелеккә йомгак ясаганнар. Быел шушы чорда барлыгы 1 миллион 393 мең тонна сөт (узган елдагыга карата – 110%) җитештерелгән. Бер сыердан уртача 6 мең 476 кг сөт савып алынган.

1 ноябрь мәгълүматлары буенча, республикада 628 мең баш мөгезле эре терлек, 458 мең баш дуңгыз (үсеш – 1%), 53 мең баш сарык һәм кәҗә, 19,4 мең баш ат, 14,5 мең баш кош-корт (үсеш – 4%) бар.

Мөгезле эре терлек Минзәлә, Бөгелмә, Кукмара, Алабуга, Балтач районнарында барыннан да күбрәк арткан. Әтнә һәм Мамадыш районнарында да сизелерлек үсеш күзәтелә, 26 районда исә сыерларның баш саны кимегән. Аеруча Яңа Чишмә, Алексеевск, Актаныш, Яшел Үзән, Апас һәм Теләче районнарында.

Илдар Мөхәммәтҗанов



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

БРИЛЛИАНТЛАР ЧҮПКӘ ӘЙЛӘНГӘНДӘ

Bloomberg агентлыгы глобаль кризисның тагын бер билгесе турында чаң суга: алмаз тармагында ихтыяҗ кими һәм бәяләр төшә. Асылташларны күпләп сату бәясе 20 процентка түбәнәйгән, ә эшкәртелгән бриллиантлар 35 процентка ук арзанайган.

De Beers – табигый алмаз чыгару, эшкәртү һәм сату белән шөгыльләнүче халыкара корпорация 400–500 миллион долларлык асылташ сатарга ниятләгән булса, барлык төзелгән килешүләрнең гомуми суммасы 80 миллион доллар гына тәшкил иткән. Корпорациянең статистика игълан ителә башлаганнан соң, пандемиянең беренче көннәрен исәпкә алмаганда, беркайчан да бу кадәр аз алмаз сатканы булмаган.

Икътисад корабының төпкә китәргә җыенуын башка фактлар да раслый. Кытайлар һәм японнар АКШның корпоратив бондларыннан (кыйммәтле кәгазьләрдән) рекордлы темплар белән котылалар. Германия экспорты кискен темплар белән кими. Норвег кронасы еврога карата кыйммәтен югалта. Көнбатыштагы кайсы гына илне алып карасаң да, финанс-икътисад проблемалары эчендә чәбәләнә.

Газзәдә барган суеш Көнбатышта сәяси тетрәү булып кайтаваз бирә. Протест демонстрацияләре туктамый гына түгел, киңәя һәм масштаблырак була бара. Илон Маск – инвестор-спекулянт дүшәмбедә генә Европада гражданнар сугышы башланмагае дип фаразлады. Эш аңа ук барып җитмәс, билгеле, әмма санкцияләр кертеп, башкаларны куркытып гадәтләнгән көнбатышлылар үз товарларына бойкот белән очраша. Мөселман дөньясы Израильне яклаган компанияләрнең товарларын сатып алмаска чакыра. Рәсми булмаган бу урам чакыруы үз нәтиҗәсен бирми калмый. Искә төшерик әле: Mastercard һәм Visa тәкәббер рәвештә Россияне ташлап чыканнар иде. Ул тәкәбберлекләре аларга бумеранг булып әйләнеп кайта. Төрекләр Mastercard һәм Visa карталарыннан баш тарта. Моңарчы шуларның карталары белән түләгәндә, табышның 4 проценты түләү системасын ясаган компанияләргә китә иде. Хәзер ул базар кысыла. Акча күчерү системаларына монополия җимерелеп төшү алдында. Төрекләр үзләренең Troy түләү системасына торган саен күбрәк күчә.

Мөселман илләреннән Бангладеш рәсми рәвештә Израиль компанияләре белән хезмәттәшлек итүчеләрне җинаять җаваплылыгына тартачагын игълан итте. Илнең тышкы эшләр министры башка илләрне дә бойкотка кушылырга чакыра.

Халыкара сәүдә базарында эшләр болай да шәп түгел. Контейнерлар белән диңгездән йөк ташу бәясе 11 тапкыр түбәнәйгән. Бигрәк тә Кытайдан Европага йөк ташу очсызланды, ди белгечләр.

Россиядә

БЕНЗИННЫ ЧИТКӘ САТАБЫЗ – БӘЯ КҮТӘРЕЛӘ

Мәгълүмат кырында Россия Хөкүмәтенең бу атнадан бензин һәм дизель ягулыгын экспортлауга чикләүләрне бетерүе турында яңалык күренде. Аны чит ил агентлыклары хәбәр итте. Хәбәр дөрес булырга тиеш, чөнки мотор ягулыгына бәяләр янә үсә башлады.

Дүшәмбе көнне дизель ягулыгының биржа бәясе 1,3 процентка күтәрелде. Бу хәл алтынчы сессия рәттән дәвам итә. Бензин дә кыйммәтләнде. Язманы саннар белән чуарлап тормыйбыз. «Ни өчен?» дигән сорауга җавап кына эзлик. Экспорт рөхсәт ителмәсә, гаҗәп хәл урнаша: нефть эшкәртү заводларын туктатырга туры килә, чөнки дизель ягулыгы белән барлык резервуарлар тула. Бәя күтәрелү урынына дефицит куркынычы пәйда була. Аннан соң үзкыйммәттән түбән бәягә товар сатуга бизнесны берничек тә күндерә алмыйсың. Демпфер да аз булыша, күрәсең: нефтьчеләр эчке базарда бензин сатканда югалтулардан зарлана. Экспортка рөхсәт бирү белән, икеләтә табыш алырга теләүче спекулянтлар мәйданга чыга: ягулыкны эчке базарда саттык дип демпфер түләве алалар да кыйммәткәрәк читкә озаталар. Хәл итү кыен булган әлеге проблемаларны хөкүмәт нинди ысул белән чишәр, киләчәктә күрербез. Ягулык акрынлап кыйммәтләнә барыр, мөгаен.

Ягулыкка бәйле башка күңелсез хәбәрләр дә ишетелә. Россиянең Urals сортлы нефте 60 долларлык диапазонга кайтып килә. Дүшәмбе көнне Приморскида аның бәясе 66,19 доллар булды, диделәр. Бу – 25 июльдән соң иң түбән күрсәткеч. Дөнья базарында «кара алтын»га бәя төшү үз сүзен әйтә, башка кайбер сәбәпләр дә бар.

Җир мае агымнарын Көнбатыштан Көнчыгышка бору үз проблемаларын тудыра. «Транснефть» Кытайга нефть кудыру күләмнәрен даими рәвештә киметә. Кузбассның электр челтәрләрендә бик еш өзеклекләр була, үз чиратында алар нефть кудыру компаниясенең насосларын туктатып торырга мәҗбүр итәләр. Электр челтәрләрендә өзеклекләр исә тимер юлдан товар ташуның артуына бәйле, диләр. Кыскасы, тимер юлчылар электр челтәрләрен гаепли, электр челтәрләре гаепне тимер юлчылар өстенә аудара. Инфраструктураның Көнчыгыш белән ул күләмдә сәүдә итүгә көйләнмәве тудыра проблеманы. Вакыт белән хәл ителә торган мәсьәлә, әмма инвестицияләр таләп итә.

Без бензин һәм дизель ягулыгы проблемаларыннан интеккән вакытта, Еврокомиссия санкцияләрнең уникенче пакетын әзерләп бетерде. Анда нефтькә һәм алмазга яңа чикләүләр бар, диләр.

ЧУТЛЫЙСЫ ДА ТҮЛИСЕ

Көн кадагында

9,1 миллиард сум. Татарстанда яшәүчеләргә быел әнә шулкадәр милек салымы салганнар. Аны 1 декабрьгә кадәр түләп бетерү шарт. Бу хакта Татарстан Министрлар Кабинетында узган брифингта искәрттеләр.

Күзен чебешләрне генә түгел, салымны да санныйлар. Торак йорт, фатир, бүлмә, гараж, машина кую урыны, тәмамланмаган төзелеш объекты кебек күчемсез милеккә салымны түләп бетерергә санаулы көннәр калып бара. Узган ел өчен агымдагы елның 1 декабренә кадәр хисап тотабыз.

– Татарстанда яшәүчеләргә милек салымын түләүгә бәйле 2 миллион 238 мең хат җибәрдек, – диде Салым федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе Марат Сафиуллин. – Шул исәптән 985 мең салым хәбәре электрон рәвештә «Салым түләүченең шәхси кабинеты» аша юлланды. Билгеле булганча, илдә яшәүчеләр быелдан башлап электрон салым хәбәрен Дәүләт хезмәтләре порталы аша да алырга мөмкин. Республикада яшәүче 80 мең кеше әлеге яңалыктан файдаланды инде.

Быел Татарстан халкына 9,1 миллиард сум күләмендә милек салымы салганнар. Узган ел белән чагыштырганда, бу 500 миллион сумга күбрәк. Барлык салым акчасының яртысыннан артыгы, тәгаен әйтсәк, 5 миллиард сумы транспорт салымына туры килә. Быел 1 миллион 23 мең машина хуҗасына салым хаты юллаганнар. Күчемсез милеккә – 2,8, җир кишәрлекләренә 1,3 миллиард сум салым салынган.

Марат Сафиуллин республика халкының быелтыр уртача ничә сум салым түләгәнлеген дә санап күрсәтте.

– 2022 ел нәтиҗәләре буенча, Татарстанда бер салым түләүчегә, уртача алганда, 1276 сум җир салымы,



krd.ru

1802 сум күчемсез милек салымы, 4896 сум транспорт салымы туры килгән, – диде ул.

Салым хәбәре кәгазьдә килергә тиеш булып та, аны шушы көнгә кадәр алмаучыларга салым инспекциясенә мөрәҗәгать итәргә киңәш бирде Марат Сафиуллин.

– Милекчеләргә салым органнарыннан хат килмәүгә өч кенә төрле сәбәп булырга мөмкин. Салым күләме 100 сумнан азрак тәшкил итсә, гражданинның салым түләүдән азат итүче ташламалары булса яки моңа кадәр салымны артык түләп, бердәм счетта бу ел өчен исәп-хисап ясарга җитәрлек күләмдә акча сакланса, борчылырга сәбәп юк, – диде ул.

Балалар салым түләүдән азат ителми, дип тә әйттеләр. Яңа туган сабыйга фатирдан өлеш бүлеп биргәнсез икән, димәк, милек рәсмиләштерүнең икенче елында аңа да салым органыннан «сәлам хаты» киләчәк. Балигъ булмаган балалар өчен исәп-хисапны әтиәниләр ясый. Салымны вакытында түләмәсәң, әҗәтнең – 20, ә моны белә торып та эшләмәү расланган очракта 40 проценты күләмендә штраф салырга мөмкиннәр. Моннан тыш, салым түләргә соңга калган һәр көн өчен Үзәк банкның рефинанслау ставкасының 1/300 өлеше күләмендә пеня исәпләнәчәк. Ул, бурычны каплаганчы, көн саен «тамып» торачак. Белгәнебезчә, салым бурычы зур булган намуссызларны илдән дә чыгармыйлар. Марат Сафиуллин әйтүенчә, бүген Татарстанда «кара исемлек»тә 12 меңгә якын кеше бар.

Хөкүмәт йортында салым түләүгә бәйле тагын бер мәсьәләгә ачыклык керттеләр. Быел салым хатларында Тула шәһәре банкы реквизитлары күрсәтелгән. Бу уңайдан «ВТ» укучылары да: «Безнең акча ник чит шәһәргә китә?» – дип борчылып шалтыратты.

– 2023 елның 1 гыйнварыннан салымнарны түләү бердәм счет аша башкарыла. Шул сәбәпле, барлык салым түләүләр Тула шәһәре казначылыгы аша уза. Барлык түләүләр шунда эшкәртелеп, үзебезнең төбәк бюджетларына күчәчәк. Акча чит шәһәрдә калмый, – диде Марат Сафиуллин.

Кем әйтмешли, салымнарны түләгез дә тынычлап йоклагыз. Соңгы мәгълүматларга караганда, барлык салынган салымның 4,8 миллиард сум чамасы түләнгән инде.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Салым түләүдән кемнәр азат ителә?

Иң беренче чиратта – пенсионерлар. Салым түләүдән азат ителүчеләр категориясенә Советлар Союзы һәм Россия Геройлары, өч дәрәҗәдәге Дан ордены белән бүләкләнүчеләр, I һәм II төркем инвалидлар, тумыштан инвалидлар, инвалид балалар, Бөек Ватан сугышында, хәрби операцияләрдә катнашучылар һәм башкалар керә. Моның өчен кайбер шартлар үтәлергә тиеш. Шулай ук ташлама милекнең һәр төре буенча салым түләүче үзе сайлап алган бер объектка карата гына кулланыла. Мәсәлән, пенсионерның ике фатиры, машинасы һәм гаражы бар икән, фатирларның берсе өчен салым түләргә туры киләчәк. Җир салымына килгәндә исә, пенсионер 6 сутый җир өчен түләүдән азат ителә, салымны шуннан арткан мәйдан өчен генә түли. Күпбалалы гаиләләр дә милеккә салым түләү буенча ташламага ия. Алар һәр бала өчен йортның – 7, фатирның 5 квадрат метр мәйданы өчен генә түли.

100 көннән соң киләчәк

Тарихи вакыйгага кадәр 100 көн калды. Билгеле булганча, киләсе елда Казанда «Киләчәк уеннары» халыкара турниры узачак. Тарихта да, Татарстан башкаласы өчен дә беренче.

Спортның без белгән гадәти төрләрен һәм киберспортны берләштергән бу турнир 2024 елның 21 февраленнән 3 мартына кадәр узачак. Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Дмитрий Чернышенко сүзләре белән әйтсәк, бу ярышларның ничек узачагын һәм нинди буласын барысы да күрергә тели.

– Без галәмдә дә беренче булдык һәм кешелек тарихында беренче булып мондый уеннарны үткәрәбез. Барыбыз да шушы уеннарның нинди булачагын белергә тели инде. Сынау ярышларын үткәрдек, анда 40 ил катнашты. Киләсе ярышларга 100гә якын ил киләчәк, – диде ул Мәскәүдә узган «Киләчәк уеннарына – 100 көн» чарасында.

Уен булгач, талисман да кирәк. «Киләчәк уеннары»ның символы итеп Бәхет кошы Мираны (Жар-птица Мира) сайладылар. Аны Татарстан студентлары эшләгән. «Мира дигән йолдыз иң борынгы космик җисемнәрнең берсе булып санала. Аңа – 6 млрд ел. Мира, латинчадан тәрҗемә иткәндә, гаҗәеп дигәнне аңлата. Без йолдыз белән кош арасында бәйләнеш таптык», – дип аңлаттылар тантана вакытында.

Уеннарның төп трофее исә бүгеннән озын сәяхәткә кузгала. Ул Россиянең 7 шәһәрендә булачак, галәмгә дә очачак. 18 ноябрьдә аны Казанга алып киләчәкләр. Трофей Иннополиста, «Урам» паркында, IT паркта кунак булачак. 1 декабрьдә исә аны Байконурдан галәмгә җибәрәчәкләр. Уеннарның төп бүләге 2024 елда гына Җиргә, ягъни Казанга әйләнеп кайтачак.

vk.com/gamesofuture

Владимир ПУТИН, Россия Президенты:

– Спортның классик төрләрен һәм киберспортны берләштергән бу турнир Россиянең яңалыкка ачык булуын, шулай ук безгә хас үзенчәлекне һәм заманчалыкны берләштерә алуын тасвирлый. «Киләчәк уеннары» катнашучылары һәм кунаклар, Казанга килеп, үзләре үк күрә алачак. Без күптөрлелекне, шул исәптән спорттагысын да кадерлибез. Спорт ул – гаделлек, тигезлек һәм гуманлылык, илләр һәм халыклар арасындагы үзара аңлашуны ныгытучы символ. Барыгызны да шушы уникаль спорт бәйрәмендә катнашырга чакырам! Казанда очрашканга кадәр!

(«Киләчәк уеннары» катнашучыларына юллаган видеосәламеннән)

КАЛФАК ЧИГЕП КЕНӘ ТЕЛ САКЛАНМЫЙ

< Ахыры. Бышы 1 нче биттә

Төрле тәкъдимнәр белдерүчеләр дә булды. Чувашиядәге Тукай авылы мәхәлләсе имам-хатыйбы Наил Ямалетдинов татар мәктәпләре өчен ислам мәдәнияте буенча татарча дәреслек булдыруны сорады. Билгеле булганча, илнең барлык мәктәпләрендә 4 нче сыйныфларда «Дини мәдәниятләр һәм дөньяви этика нигезләре» дигән фән укытыла. Бу фәнне сайлау ирекле. Теләгән укучы православие, будданы, теләгәннәр ислам нигезләрен өйрәнә ала.

– Ислам мәдәнияте буенча федераль белем стандартларында расланган яхшы гына китап бар, әмма ул рус телендә. Бу фәнне татарча укыту кирәк. Чит төбәкләрдә аеруча мөһим. Югыйсә укучылар пәйгамбәрне – пророк, иманны вера дип өйрәнәчәк. Татарстан, федераль органнар белән бергәләшеп, мондый дәреслекне федераль исемлеккә кертсә, яхшы булыр иде, – дип теләген җиткерде Наил Ямалетдинов.

Уфа фән һәм технология университетының Стәрлетмак филиалы татар һәм чуваш филологиясе кафедрасы мөдире Илсур Мансуров та борчыган проблемалары белән уртаклашты.

– Соңгы елларда туган телне өйрәтүне гаиләгә аударып калдырырга тырышалар. Әлбәттә, аның нигезе гаиләдә салына. Әмма шушындый катлаулы мәсьәләне артык гадиләштереп, аны гаиләгә генә сылтап калдыру – җаваплылыктан котылырга тырышу түгелме? Укучыларның күбесеннән: «Бакчага йөргәнче туган телне яхшы белә идем, аннан оныттым», – дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Димәк, гаиләдә татарча сөйләшкән бала да бакчада телен оныта. Менә проблема кайда! – дип борчыла галим. – Соңгы елларда авылларда да балалар туган телләрен оныта башлады. Ә бит татар телен өйрәтү өчен нинди генә заманча дәреслек, кулланмалар юк! Әмма ни хикмәт, балалар барыбер русча сөйләшә. Чөнки бала бакчада, мәктәптә алган белемне гаиләдә камилләштерергә тиеш. Һөнәри белемне дә туган телендә алса, тагын да яхшырак. Инде хәзер көллият, вузларда милли бакча һәм мәктәпләр өчен тәрбиячеләр әзерләмиләр. Укытучылар өчен милли бүлекләр дә юк дәрәҗәсендә. Бу да борчый мине.

Сәрия МИФТАХОВА



«ВТ» архивыннан

ТАТЛЫ УҢЫШ

Татарстан кырларында иң соңгы культуралар – көнбагыш һәм кукурузны җыеп алу дәвам итә. Аграрийларның шикәр чөгендерен дә ташып бетерәсе бар. Сентябрьнең коры килүе әлеге төр культураны алуда да берникадәр авырлык тудырган иде. Октябрь яңгырлары вазгыятьне үзгәрткәнме? Игенчеләр уңыш күләменнән канәгатьме? Без шуны белештек.

Узган ел белән чагыштырганда, быел Татарстанда шикәр чөгендере үстерү мәйданнары, 2,4 мең гектарга артып, 52,5 мең гектарны тәшкил итте. Әлеге культураны Минзәлә, Зәй, Буа, Тәтеш, Апас районнары күбрәк чәчте. Республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәгълүматлары буенча, хәзерге вакытта 1,7 млн тонна татлы тамыразык җыеп алынган. Бу – барлык мәйданның 98 проценты дигән сүз. Буа, Тукай һәм Тәтеш районы кырларыннан 700 мең тонна уңышны ташып бетерәсе бар.

– Бүгенгә заводка 215 мең тонна шикәр чөгендере кайтарылды. Тагын 115 мең тонна уңышны кайтарасы, шуның якынча 20 мең тоннасын казып аласы бар әле, – диде Буа районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Ранис Габитов. – Быел, үзегез беләсез, көз башы бик коры килде. Җирдә дым җитмәгәч, шикәр чөгендере болай да сусыл түгел. Киптереп тә булмады, шунлыктан уңышны җыеп алу һәм казу авырлык белән барды. Октябрьдә, киресенчә, яңгырлар күп булу сәбәпле, эшләр тоткарланды.

Аның каравы җыеп алынган уңыш сөендерә.

– Без канәгать. Уртача уңыш узган еллар белән чагыштырганда бер дә ким түгел. Шуңа күрә быел да шикәр чөгендереннән яхшы уңыш җыеп алдык, дип әйтә алабыз, – диде идарә башлыгы.

Коры сентябрь татлы тамыразык өчен генә түгел, уҗым культуралары өчен дә бик начар булган иде. Хәзер инде октябрь яңгырларына өметләнәләр.

– Көзге культураларның 70 проценты тишелә алмыйча ята иде, яңгырлардан соң алар да җанланды. Тик әлегә ничек кышлыйсыларын әйтеп булмый. Кышка ничек керерләр дә язга ничек чыгарлар – алдан ниндидер нәтиҗәләр ясарга иртәрәк, – диде ул.

Шикәр заводларында да эшләр тулы куәтенә бара. Хәзерге вакытта республиканың шикәр заводларына эшкәртүгә 1 млн тонна чимал кайтарылган. Сезон башыннан бирле аларда 119,7 мең тонна шикәр җитештерелгән.

– Чимал күп булганлыктан, Буа шикәр заводы ике тапкыр эшчәнлеген вакытлыча туктатып торды. Хәзер эшләр үз тәртибе белән бара, – диде Ранис Габитов.

Шунысын да әйтергә кирәк: республика халкына 100 мең тонна тирәсе шикәр җитә. Белгечләр аның бәясе арту өчен дә сәбәпләр юк, дип ышандыра. Республикада узучы көзге ярминкәләрдә шикәрнең бер килограммын 60–65 сумнан саталар.

– Быел шикәр җитештерү чыгымнары бик зур темплар белән артмады, – дип аңлаттылар безгә Авыл хуҗалыгы министрлыгының матбугат үзәгендә. – Хуҗалыклар быел ашлама кертү күләмен арттырды. Тик кайвакыт бәя күтәрелүгә объектив булмаган факторлар да йогынты ясарга мөмкин. Әйтик, узган ел бар халык кибетләргә шикәр алырга йөгергәндә, сату күләме 16 тапкыр артты һәм бәяләр бермә-бер өскә сикерде.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Табигать нигъмәте

Сырганак

Сырганак составындагы май һәм каротин яман шеш авыруларына каршы көрәштә нәтиҗәле дәва чарасы булып тора. Каротин – майларда эрү үзлегенә ия витамин, шуңа күрә ул сырганак җиләкләрендә эрегән халәттә була. Кайбер илләрнең галимнәре каротинның рак күзәнәкләре үсешен туктата торган табигый киртә булуын ачыкладылар. Бер тәүлектә кабул ителгән 6 миллиграмм шушы витамин профилактика өчен бик җитә.



Витаминнар җыелмасы буенча сырганакка җиткән үсемлек юк. Ә сырганак мае исә могҗизалар тудыру кодрәтенә ия. Аның белән кояшта янган, пешкән, өшегән урыннарны, начар төзәлә торган яраларны, тире туберкулезын, колак, тамак һәм борын шешләрен, тимрәү, гиповитаминоз һәм авитаминозларны, күз авыруларын һәм башка чирләрне дәвалыйлар. Үңәч яман шешен нур терапиясе белән дәвалаганда да сырганак маен кулланалар. Ул авыртуны баса, башка бик күп шифалы үзлекләргә ия.

Ләкин сырганак мае барлык кешегә дә файдалы түгел. Мәсәлән, аны холецистит белән авыручыларга, ашказаны асты бизе белән изаланучы өлкән кешеләргә эчәргә ярамый.

Сырганак мае гайморитның кайбер формаларын дәвалаганда да яхшы чара исәпләнә. Аны шулай ук дәвамлы фарингиттан һәм ларингиттан дәвалаганда да тәкъдим итәләр. Йөткерүдә канлы лайлалы катламын сырганак мае сеңдерелгән мамык белән майлау һәм сырганак мае белән ингаляция ясау нәтиҗәсендә 10–12 көннән соң авырулар үзләрен бик әйбәт хис итә башлыйлар (ингаляциянең бер сеансы 15 минут дәвам итә).

Пародонтитны дәвалаганда, казналарга сырганак маенда чылатылган җеп куела.

Кара миләш

Кара миләшнең дәвалау үзлекләре шактый. Мәсәлән, аның составында капиллярларны ныгытучы Р витамины кара карлыгандагыга караганда 2 мәртәбә күбрәк. Шуңа да әлеге витаминны эшләп чыгарганда кара миләшне төп чимал итеп алалар. Аның җимешләрендә йод та күп.

Дәвалау максатыннан аны витаминнар җитмәгәндә, бөердә таш булганда, гипертония, цистит вакытында кулланалар.

Пешкән кара миләш кан агуны туктата, эчне йомшарту, сидек кудыру үзлегенә ия. Ә кипкән җимешен дизентерия вакытында кулланырга киңәш итәләр.

Гипертония һәм атеросклерозны дәвалау өчен, 1 кг кара миләшне 700 г шикәр комы кушып изәргә кирәк. Шуны көнгә ике мәртәбә 75–100 г ашарга.

Геморрой вакытында бер үк күләмдә алынган кара миләш белән балны кайнаталар да шуны көненә 3 мәртәбә ашарга 30 минут кала 100 г кабалар.

Витамин җитмәгән чорда 1 чәй кашыгы кипкән миләшкә 400 мл кайнар су коеп, 4 сәгать төнәтергә һәм көненә 2–4 мәртәбә 1әр стакан эчәргә.

Организм арыганда, азканлылык булганда һәм сидек кудыру өчен, 2 чәй кашыгы кипкән кара миләшкә 400 мл кайнар су коеп, 1 сәгать төнәтергә дә шуңа берәз шикәр комы өстәргә. Төнәтмәне көн дәвамында 3–4кә бүлеп эчәргә.

Эч киткәндә 1 аш кашыгы кипкән кара миләшкә 1 стакан кайнар су коеп, 30–40 минут төнәтергә һәм көненә 3–4 мәртәбә яртышар стакан эчәргә.

Эч китү, дизентерия, ашказаны, эчәкләр авыртканда, гипертония вакытында көненә 3 мәртәбә ашарга 30 минут кала 100 мл яңа сыгылган кара миләш согы эчәргә мөмкин.

Ел дәвамында кара миләш, гөлҗимеш һәм кара карлыган чәе эчәргә кирәк. Дәвалаучы чәй пешерү өчен, 1 аш кашыгы җимешләргә 1 стакан кайнар су коярга кирәк. Дөрес, бу чәйне 15–20 минут кына түгел, 4–5 сәгать пешерергә кирәк. Көненә 3–4 стакан шул чәйне эчәргә мөмкин.

Кара миләшне гастрит, ашказаны һәм уникеилле эчәк җәрәхәте вакытында 3 атнадан артык кулланырга ярамый.

Лилия Әскәровадан кыздырылган каз рецепты

Татар халкының бер генә бәйрәме, туе да кыздырылган каздан башка үтми. Үзәмнең рецепт белән бүлешим әле. Бик тәмле килеп чыга.

1 каз өчен 10 литр суга 1 кг тоз салып, эремә ясыйсың һәм казны шул суда 1 тәүлеккә калдырасың. Аннан соң, тозлы судан алып, алдан әзерләнгән катнашма сылыйсың.

Катнашманы түбәндәгечә әзерлим: бер чынаякка 1 чәй кашыгы аджика, 1 аш кашыгы бал, 1 аш кашыгы соя соусы, 3 аш кашыгы майонез, 3–4 тырнак сарымсак, 1 кап тавык өчен тәмләткечләр, 1 афлисун согы салып болгатам. Шул катнашма белән казның эчке һәм тышкы ягын яхшылап сылап, 10–12 сәгать бүлмәдә тотам. Аннан соң казны җиңсәгә урнаштырып, 180-200 градуслы мичтә 2–2,5 сәгать пешерәсе (җиңсәнең өстен берничә урыннан тишкәләргә кирәк). Пешеп җитәр алдыннан, каз кызарып матур булып пешсен өчен, җиңсәнең өстен кисеп, 10–15 минут тотасы.

Балан

Баланда С витамины лимондагыдан 1,5 тапкыр күбрәк. Анда аскорбин кислотасын үзләштерергә ярдәм итүче Р витамины да бар. Салкын тигәндә шуңа да баланның файдасы зур. Грипп эпидемиясе вакытында, салкын тидерү куркынычы булганда балан белән дәваланырга була.

Балан – табигый антисептик. Тамак авыртканда аны балан согы яки төнәтмәсе белән чайкарга мөмкин.

К витаминына бай булу сәбәпле, йөрәк һәм кан тамырларын чистарта, кан басымын төшерә. Гипертониядән интегүчеләр балан белән дуслашсын.

Игътибар итсәгез, баланның орлыклары да йөрәк формасында. Табигать үзе үк аның файдалы булуын сиздерә.

Балан тынычландыру үзлегенә ия. Йокларга ятар алдыннан 1 стакан балан морсы эчсәгез, уянмыйча йокларсыз.

Баланда А витамины күп, ул күз күрүен яхшырта. Әмма бета-каротин үзләштерелсен өчен, май кирәк. Балан ашаганда бер кашык каймак кабып куярга онытмагыз.

Балан эч китүне дә туктата. Агулану, энтерит, колиттан дәваланырга ярдәм итә.

ТАТАРСТАН ВЕТЕРАНЫ
Республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы советы һәм «Ватаным Татарстан» газетасының уртак кушымтасы.
Чыгарылыш өчен җаваплы – Гөлгенә ШИҺАПОВА. Битка салучы һәм бизәүче – Марат ХӘБИБУЛЛИН.
Безнең адрес: Казан шәһәре, Театр урамы, 5 й.
Телефон: 8(843) 238-16-88
Электрон адрес: soovp.kzn@tatar.ru

ТАТАРСТАН ВЕТЕРАНЫ ВТ
№ 10–11
15 ноябрь, 2023 ел
РЕСПУБЛИКА ВЕТЕРАННАРЫ (ПЕНСИОНЕРЛАРЫ) ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ СОВЕТЫ ҺӘМ «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНЫҢ УРТАК КУШЫМТАСЫ

ФАЙДАЛЫ КИҢӘШЛӘР
Табын күрке – каз > 3

СОЛДАТ ХАТЛАРЫ
Бөек Ватан сугышы хатирәләре > 4

БӘХЕТЛЕ КАРТЛЫК
Мәдинә апаны чит балалар ташламый > 6

Пар канатлар

ТОРМЫШНЫҢ ҖАЕН БЕЛЕП

Апас

Апас районының Шәмбалыкчы авылында яшәүче Әминә һәм Азат Гыймрановларның гаилә коруларына 65 ел вакыт узган. Алар Тимер туйларын каршылаган. Азат абый белән Әминә апа биргән вәгъдәләренә тугры калып, хөрмәт-ышанычка корылган гаилә юлыннан атлый-атлый, бүгенге матур гомер көзләренә җиткәннәр. Икесе дә дин юлында, изге дога укып яшиләр.

Азат абый гомере буе колхозда эшли. Тракторчы да, комбайнчы да була. Аннан озак еллар, рульгә утырып, ерак араларны якынайта. «Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» исемен йөртә. Алган бүләкләре дә бик күп.

– Мәскәүгә кадәр бардым. Сөт ташу машинасын 20 елга якын йөрттем. Эшем белән Түбән Бияшына баргач, тормышта төп терәгем булган үз кешемне дә очраттым, – ди Азат абый.

Бия елгасы буенда ком төяргә килгән бер төркем кызлар арасыннан Азат абыйның күзләре Әминә апаны эзләп таба. Ике яшь йөрәк шул көннән сөю ялкыннарында янып, бер гаилә булып берләшә.

– Мөлаемлеге, гүзәллеге белән җәлеп итте. Бик матур сөйләшә иде. 1957 елның августында өйләнештек. Аллага шөкер, матур яшәдек. Булган үпкәләшүләрне үткәреп җибәрә белдек. Соңгы сүзләрне әйтешмәдек. Яратып яшәдем, дип әйтә алам. Олыгайгач, тагын да хөрмәт арта. Ул бит – бөтен гомерен сиңа багышлаган хатын-кыз, балаларыңның әнисе, – ди Азат абый.

> 4

Котлыйбыз!

Бабайга – 95, әбигә – 90!

Шушы көннәрдә Түбән Кама районының Сухрау авылында гомер итүче Мәрзия һәм Әхәт Галиәхмәтовлар бик матур бәйрәм уткәргән. Гаилә башлыгына 95 яшь тулган. Мәрзия апага 90 яшь икән. Галиәхмәтовларның бергә гомер итүләренә – 70 ел.

Әхәт абыйны туган көне белән котларга дип, барлык балалары, оныкларлары, онык-оныкчыклары җыелган. 3 малай, 2 кыз үстергән алар. Бу гаиләне без блогерларның сәхифәсендә еш күрәбез. Түбән Камада яшәүче килене Элфия апа да, «Татар Малае» исеме алган оныклары Ринат та өлкәннәрне еш күрсәтеп тора. «Күрсәтерлек шул алар», – ди киленнәре.

– Бу гаиләгә килеп кергәнемә 41 ел була инде. Бәхетемәдер, алар мине бик якын итеп каршы алды. Килен түгел, кызлары булдым. Бу якларда каенанага «әнкәй» диләр, әтигә «әти» дип эндәшәсе. Беренче көннән үк әнкәй белән уртак тел таптык. Миңа тыңа түгел, башка киленнәргә дә әнкәйнең бер авыр сүз әйткәне булмады, – ди килене Элфия.

Әхәт абыйны котларга авыл җирлеге башлыгы киләсен белгәч, алар тиз генә җыена да өстәл кора. Барлык якыннары бергә җыелышалар. Ихлас, матур бәйрәмгә әйләнә ул очрашу.

– Эти белән әнкәй бер-берләрен хөрмәт итеп, тынычлыкта яшиләр. Тигез, матур картаюның сәбәбе – балалар игелегендәдер. Хәсрәт кичермичә яшәү, үзләрен яратуны тою гомерләрен озайтадыр дим мин. Яшәсеннәр генә әле! Алар гомер буе тик утыра белмәде. Гел эштә, гел хәрәкәттә. Без, аллә нигә бер килеп, өй җыештырган булабыз. Әле әнкәй үзе дә тик тормый. Ялт итттереп бөтен эшне башкарып куя. Күзләр генә тимәсен аларга, – ди Элфия апа.

Әхәт абыйны котларга килгән Сухрау авыл җирлеге башлыгы Ришат Галимовка да рәхмәтле Галиәхмәтовлар. Өлкәннәрнең хәлен гел белеп тора, диләр. Туган көн белән котларга килгәч тә, баянын тартып җырлап биргән.

Тормышның җаен белеп

< Ахыры. Башы 3 нче биттә

Әминә апа – ишле, уңган-булган нәселдән. Шәмбалыкчыга килен булып төшкәч, иң элек сөт җыя. Аннан клубта техник хезмәткәр булып эшли.

Әминә апа тормыш иптәшен мактап кына телгә ала.

– Ышанычлы ир, сүзендә тора торган кеше. Азатымнан мин бик канәгать. Аның миңа ашәке сүзләр әйткәне булмады. «Кызым», дип матур итеп эндәшә, миңа булыша. Бөтен эшемдә ярдәмче. Әле хәзер дә тавык-чебиләр үстерә. Мең шөкер, тормышыбызның азагына кадәр шулай яшәргә язсын, – ди ул.

Азат абый тату гаиләсерләре белән дә уртаклашты.

– Гаиләдә хатын-кызның сүзен тыңларга, аның уй-фикере белән исәпләшергә, җаен аңларга кирәк. Авыр сүз әйтергә ярамый. Аңа ярарга тырышу үзеңне кечерәйтүгә керми. Шул вакытта тормыш әйбәт бара, – ди ул.

Әминә апа иса чиста күңелле булып, эчендә үч сакламыйча яшәргә өнди.

– Мин бер тамчы да ачу саклый белмим. Сүзгә килсәк тә, ул борылып килгәнче онытып булам. Чәй эчәргә чакырам. 65 ел сизелмәде дә. Бер уйласаң, бик күп бит инде ул. Икенче карасаң, бер мизгелдә узып киткән, – ди Әминә апа.

Гыймрановлар ике ул тәрбияләп үстергәннәр. Алар хакында да горурланып сөйлиләр. Киленнәрен дә үз кызлары кебек мактап кына торалар. Кече уллары Мансур һәм киленнәре Рузалия күршеләрендә генә яши. Олы уллары исә эти-әниләрен тәрбияләргә Мәскәү өлкәсеннән кайткан.

– Әти-әни белән горурланып яшибез. Бер-беребезнең хәлен белеп, якын итеп торабыз. Сыйларыбыз да, пешкән ризыгыбыз да уртак. Кая барсак та, алар дә әйтеп йөрибез. Аерым яшәсәк тә, бергә яшәгән кебек, – диләр Мансур абый белән Рузалия апа.

Ләйлә ИСКӘНДӘРОВА

ЗӨЛХИЯ КЕБЕКЛӘР СИРӘК

...Ул, соңгы курста укыганда практикага Мөслимгә кайтып, үзенең беренче спектаклен сәхнәләштерә. Бу спектакльне карап бәяләргә язучы-драматург, институттагы остазы Рабит Батулла килә. Ул үз шәкертенең эшен югары бәяли, аның алдагы иҗади тормышына юллама бирә.

Әле кулына диплом да алып өлгермәгән, энергиясе ташып торган кызны район халык театрының режиссеры итеп билгеләп тә куялар. Ул спектакльләрне сәхнәләштереп кенә калмый, төп рольләрне дә үзе башкара. Районда бер генә мәдәни чара да аннардан башка үткәрелми: үзе үк кичә-концертларга сценарийлар яза. Сузем – Азнакайда гомер итүче, Мөслим районының Вәрәшбаш авылы кызы Зөлхия Миңнеханова турында.

– Урта мәктәпне бетергәч, Казанга китеп, мәдәният институтына кердем: режиссер һөнәре алып чыктым. Тагын туган районыма кайтып, эшкә урнаштым... Бер концертта күрше Азнакай егете Рәис белән очраштык. Мин 1976 елда Азнакайга килен булып төштем, – дип искә ала Зөлхия ханым.

Азнакайда да тик тормый ул. Халык театры режиссеры, нефтьчеләрнең Мәдәният һәм техника сараенда булек мөдире, шәһәр мәдәният бүлеге җитәкчесе, район мәдәният идарәсе җитәкчесе урынбасары, район-шәһәр мәдәният сарае директоры...

– Азнакай минем өчен бик кадерле, туган ягым кебек... Биредә мин бәхетемне таптым, тамыр җәйдем, гаиләм гөрләп чәчәк атты, яраткан һөнәрем буенча эшләп, зур уңышларга ирештем. Районыбыз оешуга 90 ел булды. Шуның нәкъ яртысы – 45 еллык тарихында минем дә шактый гына саллы өлешем, эзем бар дип саныйм, – ди ул. – Тәрле чаклар булды инде, апаем. Безнең өлкәдә бит бары фанатиклар гына эшли ала. Ни ялы, ни бәйрәме юк дигәндәй... Хезмәт хакы белән дә мактана алмыйбыз. Дәүләтебез безнең һөнәр ияләренең хезмәтен бүген дә әле тиешенчә бәяләп бетерми. Көн дә кеше күз алдында булгач, матур итеп киенергә дә, үз-үзеңне карарга да, гаиләңне киендерергә, ашатырга да кирәк бит! Әгәр, кулымнан килсә, гомерләрен мәдәниятькә багышлаганнарның һәрберсенә һәйкәл куяр идем.

Зөлхия апа пенсиягә чыккач, Рәисе белән бакчада казынып, чит илләргә барып яшәрбез дип хыялланә. Тик Рәисе генә озак яшәми, үлеп китә. Әмма тынгысыз күңелне бернишләтеп булмый. Аны кабат чакырып, үзе оештырган балалар театр студиясе эшен дәвам итүен сорыйлар. 15 ел элек эшли башлаган «Тылсым» студиясе «Халык театры» дәрәҗәсенә ирешкән. Уңышлары да шактый: куйган спектакльләре белән «Иделкәем» театр конкурсларында да, нәфис сүз бәйгеләрендә дә призлы урыннар алып киләләр. Кайларда гына булмаган алар. Россияне аркылыга-буйга иңләп, Сыктывкар, Түбән Новгород, Чабаксар, Мәскәү, Пенза, Санкт-Петербург, Чиләбе, Волгоград, хәтта чит илләрдә – Венгрия, Төркия шәһәрләрендә дә ансамбльләре татар халык җырларын яңгырата.

Зөлхия ханым татар теле өчен дә борчылуын җиткерде. Туган телне сакларга иде, ди ул.

– Без бит совет чорында тәрбияләнгән кешеләр. Минемчә, бүген иң катлаулы, ләкин иң мөһиме – үзебезнең татар икәнлегебезне онытмау, туган телебезне саклау. Бүгенге кебек битраф булсак, бөтенләй югалтабыз бит ана телебезне! Кая барабыз? «Уян, татар!» – дип кычкырасы килә. Милләт буларак сакланып калу өчен, иң мөһим әйберләр: дин, тел, мәдәният! Менә шушы өч әйберне берләштергән кыйблабызны югалтмаска иде, – ди инде 10 елдан артык Азнакайда Бөтендөнья татар конгрессы булекчәсен дә җитәкләүче Зөлхия ханым.

Зөлхия ханым тормышын яратып, янып яши. Әле менә тормышында зур үзгәреш тә булган, язмыш аны отставкадагы милиция полковнигы белән таныштырып, кавыштырып куйган.

– Тормышны яратып яшик. Үзебездән соң матур эшләр калдырыйк, – ди Зөлхия ханым.

Алсу ГАБИТОВА. Азнакай

ОЗЫН ГОМЕРНЕҢ СЕРЕ – САБЫРЛЫКТА

Апас районы Шыгай авылында туган Саимә әби Якуповага 101 яшь тулды.

Иркәләнеп үсәргә туры килмәгән аңа. Ятимлеген дә, ачлыгын да, авырлыгын да бик күп татыган. Яшьтән үк әти-әнисез калып, 15 яшеннән нужа арбасына җигелгән. Сынауларны сабырлыгы, тырышлыгы белән җиңгән.

– Гомер буе колхозда эшләдем, хезмәттән курыкмадым. Ни кушсалар, шуны эшләдем. Төрле эшләр башкардым. Бригадир да булырга туры килде, – ди ул үзе.

Саимә әби чаялыгы, гел хәрәкәттә булуы белән дә аерылып торган. Җәмәгать эшләренең үзәгендә кайнаган, сәнгатьне үз иткән. Җырларга, спектакльләрдә уйнарга яраткан.

– Үз күңелебезне күтәреп яшәдек. Боегып, елап утырмадык. Кыен чорлар туры килсә дә, күңелле мизгелләрен сагынып искә алам. Озын гомеремнең серен дә сабырлыкта, көр күңел белән яшәүдә күрәм, – ди акъәби.

Олы йөрәкле, мәрхәмәтле җанлы да ул Саимә әби. Авылдашы Хәнифулланың тормыш иптәше вафат булгач, аның өч баласын да үз кочагына сыендырган. Үзе дә ике балага гомер биргән. Барлык балаларын да тигез күреп, күңел җылысын, кайгыртуын бердәй өләшкән. Бүген исә кадерле әни, бәхетле әби булып, Осиново бистәсендә кызы Фәнисә гаиләсе белән гомер кичерә.

– Әниебез үз аңында, үз акылында. Үз җае белән йөри, безгә киңәшләрен бирә. Яшьлеген сагынып җырлап та җибәрә. Әниебез янәшәсендә без һаман да сабый әле, – ди Фәнисә апа.

Ләйлә ШИҺАБИЕВА

«БУ МИНЕМ АКТЫК ХАТЫМ БУЛМАГАЕ»

*«Татарстан ветераны» кушымтасында Бөек Ватан сугышында катнашкан солдатларның хатларын тәкъдим итәбез. Әлеге истәлекләрне редакциягә КФУ профессоры **Марсель БАКИРОВ** тапшырды.*

< Ахыры. Башы алдагы саннарда

Сугыш сугыш инде. Андый авыр чорда хатларның бик озаклап йөрүен дә, шулай ук бер өлешенең тиешле адресатына барып ирешмәүләрен дә аңларга була. Ләкин ил язмышы кыл өстендә торган дәверда дә фронттагылар белән тылдагылар арасындагы бәйләнеш җепләре өзелмәгән. Бер-берләренең хәлләрен алар Информбюро тапшыруларына гына түгел, ә ике арада йөргән хатлар аша да белеп торганнар. Шунысы кызыклы һәм әһәмиятле: әҗәлләре аяк асларында яткан солдатларның күңелендә һәрчак Ил-йортлары һәм якыннары булган, алар шулар белән рухланып һәм шулар өчен җан атып яшәгәннәр, шулар хакына утка кергәннәр. Тагын шунысы игътибарга лаек: сугыштагылар үзләреннән бигрәк гаиләләре өчен хафаланганнар, үрсәләнгәннәр. Менә сугышка кадәр Буа районының Норлат авылында укытучы булып эшләгән Салих Сайкинның (ул 1942 елның ахырында һәлак булган) соңгы хаты. Анда ул үзенең хәле турында бик аз яза, хатның күпчелек өлеше якыннары өчен борчылу, ачыргаланулардан тора.

13 ноябрь, 1942 ел.

«Үз хәлемне җәелеп язып тормыйм. Аны үзегез дә чамалыйсыздыр: көн-төн пуля яңгыры, снаряд, бомба шартлаулары. Хәтта еш кына аш алырга да пулялар һәм миналар сызгырып-чинап торганда барабыз. Кеше түзсә дә түзә икән. Бер эш тә эшләп булмый – ил шуны сорый.

Апа! Хатларыгыз аша тормышыгыз белән танышып торам. Бик кыйммәтчелек икән. Белмим, сез ничек тә яшәрсездер. Рая бик зарланып яза: бәрәңге дә бик аз, ди. Мин аның хатын һәм карточкасын алгач, шуларга карап күземнән яшьләр акты.

Бануләрдан да хат алам, һәр хат алу бер яктан зур шатлык булса, икенче яктан – зур кайгы. Алар турында да уйлый башлыйсың, төннәр буена борчыласың. Бануларның тормышлары шәптән түгел, әлбәттә. Биш бала бит, эш көннәре юк. Алар ярдәмгә мохтаҗ, тездә генә утырган һәм кулда гына сикерткән балалар икмәккә тилмерәләрдер кебек. Мин алар өчен эчтән елыйм. Ләкин мин аларга ярдәм итүдән мәхрүм инде. Ватанны саклау бурычы михнәтләргә түзеп булса да аерым яшәүне таләп итә. Җәй көне барып хәлләрен белсәгез, юатсагыз, бер зур эшегез булыр иде.

Әй, апа!

Белсәң иде, һәрбер сүз, һәрбер юл йөрәкне сызландыра. Их, үтте, үтте вакытлар, инде сезнең белән гомергә дә бергә булмаган кебек хис итә башладым. Белмим, белмим, йөрәк сызлана, язмыш нәрсә әзерләгәндер.

Барыгызны да сагынып, бер күрергә тилмереп калучы Салих».

***

Икенче автор – Чирмешән районының Лашман урта мәктәбен тәмамлап фронтка киткән һәм кече командирлар курсын үткәннән соң лейтенант сыйфатында Сталинград, Курск – Орлов сугышларында катнашкан Рәфгать Әхтәмов. 1943 елда Орлов юнәлешендәге бәрелештә һәлак булганчы, әти-әнисенә, гаиләсенә язган хатларында ул, үзенең хәле белән таныштыру белән беррәттән, үтә сагынган нәрсәләре турында да яза. Шундый бер хаты белән танышыйк.

2 ноябрь, 1942 ел.

«Бүгенге көндә мин исән-сау. Бөтен көчен куеп, Сталинградны алырга ыргылучы немец фашистларының һөҗүмнәренә каршы торып, шәһәрне саклыйбыз. Әле менә, атыш һәм мина, снарядлар тавышы тынган арада, сезгә хат язарга булдым.

Бик еш күз алдына киләсез. Тәшкә дә кергәнегез бар. Бер көнне үземне өйдә итеп күрдем. Барыбыз да өстәл тирәсенә җыелып, бәлеш ашыйбыз икән. Мин бик тә өй ризыкларын сагындым. Катык белән бәрәңге ашыйсым килә. Ләкин иң нык юксынган нәрсәм – гармуным. Исән торамы минем тальяным? Их, мин әйтәм, бер өздереп уйнап җибәрергә иде! Катык белән бәрәңгене минем өчен дә ашагыз.

Әни, бала чагында уенчык мылтык белән уйнаганда син миңа: «Мылтыктан уйнаргә язмасын, Ходаем, сиңа», – дия торган идең. Шулай була гына күрсен иде инде».

Аларга күп кирәкми...

Чүпрәле

Күптән түгел Чүпрәле районының Иске Чокалы авылында яшәүче Халисә Миначева 90 яшен тутырды. Аны котларга балалары җыелды, Иске Чокалы авыл җирлеге башлыгы Рәмис Низамов һәм авыл ветераннары советы рәисе Гөлсирә Хәлиуллова килде.

Халисә апа – авылда иң хөрмәтле хатын-кызларның берсе. Иске Чокалыда туып-үскән, бик яшьли кул арасына кереп, тормыш арбасына җигелгән кеше ул. Гаиләдә иң олы бала булганлыктан, үзеннән соңгы туганнарын карап үстерү дә тия әле аның өлешенә. Сынатмый Халисә, һәр эштә җитез, алдынгы була. Уңган кызга авылның иң шәп егетләренең берсе булган Бабирның күзе төшә. Өйләнешәләр. Халисә апа бу вакытта «Чишмә» колхозында бозау фермасында эшли торган була. Гомере буе шул эшне башкара ул.

Миначевларның биш балалары туа. Кызганыч, Халисә апаның тормыш иптәше бик яшьли вафат була. Шушы биш баланы карап үстерү, укыту, кеше итүне язмыш тарафыннан күп тапкыр сыналган, тол калган хатын башкара. Дөрес, балалары да әнисенең сүзеннән чыкмыйлар – яхшы укыйлар, югары белем алалар. Халисә апа бүген улы Илмир, килене Айсылу тәрбиясендә гомер итә.

– Без эштән башканы белмәдек инде, – ди Халисә апа. – Авылдан читкә китеп тә йөрмәдек, балалар үстердек, алар кеше булсын өчен тырыштык. Бүгенге тормышыбызны бик канәгатьмен.

Үзен котларга килгән кунакларга да, китергән бүләкләренә дә бик шатланды ул. Хезмәт иткән елларына хөрмәт буларак крестьян-фермер хуҗалыгы җитәкчесе Альберт Низамов та бүләген җибәргән. Анысына да күңеле булды.

– Мине зурлаган өчен язмыш сезне олыласын, – ди Халисә апа.

Резедә ҖАМАЛЕТДИНОВА

50 ЕЛ МАШИНА ЙӨРТҮЧЕ:
«РУЛЬГӘ УТЫРСАМ, СЫЗЛАНУЛАР ОНЫТЫЛА»

Кукмара

«Восток-Агро» җәмгыятендә шофер булып эшләүче Мөхип абый Кәримовның эш стажы 50 елга якын. 1976 елдан бирле рульдә ул.

Аш-Буҗи авылында туып-үскән егет, мәктәпне тәмамлагач, иң элек Янил һөнәри училищесында, соңыннан автомәктәптә укый. Армия хезмәте узгач, үзләрендәге күмәк хуҗалыкка шофер булып эшкә урнаша да шуннан бирле бер һөнәргә тугры булып кала.

Ул беренче машинасы «ГАЗ-51»не әле дә хәтерли.

– Без бит эш талымлап торучы буын түгел идек, кая җибәрәләр, нинди бурыч йөклиләр – һәммәсен үтисең. Көз җитсә, иртәдән караңгы төнгә кадәр амбарларга, Кукмара элеваторына ашлык ташыдык. Кыш айларында да эшсез тилмергәнне хәтерләмим: кемгәдер ташкүмер алып кайтасы, я булмаса күрше районга маллар алып барасы... Аннары авылда җиңел машиналар булмагач, авырып-сырхаулап китүчеләрне хастаханәгә илтү өчен дә безне дәшәләр иде. Хәтта Яңа елны каршылап, икенче көнне иртүк рульгә утырган чаклар да аз булмады, – ди ул. – 47 ел вакыт эчендә ике «ГАЗ-53» машинасын алыштырдым. Аннары «КамАЗ»га утырттылар. Хәзер дә «КамАЗ» иярләгән көнем. Бу арада басуга тирес чыгарабыз.

Гомер буе йөк машинасында йөрү бер дә җиңелләрдән түгелдер. Әмма сөйләшү барышында ялгышып кына булса да ник бер уфтану, зарлану сүзе әйтсен тәҗрибәле шофер-аксакал.

– Кайвакыт иртүк сәяк-буыннар сызлаштырганда, «Их, ничек эшләргә икән бүген?» – дип куям үзе. Ә менә «КамАЗ»ыма утырып, бер рейс әйләнеп кайтуга, гәүдәм языла, сөякләр үз урынына урнашып бетә дә, күңелләр күтәрелеп китә, кичкә кадәр рәхәтләнеп эшлисең, – ди ул. – Техника бит ул ватылмыйча да тормый. Без, өлкән буын, юлга чыгасы булса, кичтән машина тәртиптәме-юкмы икәнен карарга гадәтләнгән. Юкса, трассада көе китсә, анда тәэзтү бик читен. Элек юллар бик начар иде бит. Атна-ун көн саен машина рессорын сүтеп җыюлар бүген дә онытылмый. Хәзер генә ул җырлап йөрерлек, бар җирдә диярлек асфальт. Әмма шулай да машинаны ремонтлап тору комачау итми. Запас частьлар, кирәк-яраклар белән һәрдаим тәэмин итәләр.

Мөхип абый хәзер машинаның күплегенә шаккатуын яшерми.

– Без яшь вакытта машиналар бик аз иде. Шуның өчен зур юлларда йөрү бик иркен, җайлы булды. Хәзер кайсы гына гаиләне алма, кеше саен диярлек җиңел машина. «Бөке»ләр вакытында кайбер рульдә утыручыларның сабырсызлыгы, бер-берләрен ихтирам итмәүләре күңелгә тия. Үзләрен юлның патшасы дип санаучы «батыр йөрәкле»ләр, юлны кисеп, каршыңа чыгарга да күп сорамый, – ди Мөхип абый. – Аяныч хәлләр шуннан була да инде. Онытмыйк: юл ашыкканны гафу итми, аеруча яшьләр бу турыда да уйласын иде.

Алсу СӘЛАХЕТДИНОВА

НУРГАЯЗНЫҢ КУЛЫ АЛТЫН

Чирмешән

Аңа Кара Чишмә халкы гына түгел, Туймәттән, Керкәледән, Бәркәтәдән дә киләләр. Нургаяз Ризванов пычак үткенләү остасы булырак дан казанган, аның буш вакыты бөтенләй юк. Бер караганда, нәрсәсе бар инде пычак үткенләүнең – чарга тигездең дә алдың. Алай түгел икән шул, бу эшнең дә сере, җае бар икән. Кайберәүләр үткенләгән пычак, балта ише инструментлар никтер бөтенләй кисмәскә әйләнә.

Танылган оста әйтүенчә, бу эштә иң мөһиме – чисталык.

– Пычак коры, майсыз, туры булырга тиеш. Мин үзем мал чалмыйм, әмма киштәдә бу эшкә үткенләнгән, уңайлы аерым пычак тотам. Малны бугазлау өчен аерым пычак булсын, тире салдыруга – башкасы. Пычакны сөяк ватып бозмагыз. Нәрсәдер ясарга, кисәргә, эшкәртергә гел яхшы корал кирәк, – ди ул. – Мал чала торган пычак хром кушылмалы корычтан булса әйбәт. Кухняда кулланыла торганына йомшаграк тимер дә кулай, аларны үткенләү дә ансат. Каты материалның йөзен чыгару кыен. Кайда гына кирәксә дә, үткен пычак белән эшләү хәерле, ул лезвие кебек булсын. Югыйсә бар шундый кешеләр: мал муенын әллә ничә тапкыр ышкыйлар, хайванны азаплыйлар. Алай ярамый бит.

Нургаяз 12 ел пенсиядә инде. Ул 31 ел Әлмәттәге батырма насослар заводында хезмәт куйган: детальләр шомарткан, тимер дә эреткән. Яшь чагында, шабашкада йөреп, агач эшенә дә остарган. Моның кирәге чыгып тора, 50 ел чамасы элек, әти-әнисе исән чагында салынган өйне тышкы яктан бик матур иткәннәр, мунчалары, сарайлары да яңарган. Бакчасына рәхмәт, ул нык булышты, ди.

– Аллаһы Тәгалә: «Изгелек итүдә ярышыгыз!» – дигән. Мин кемгәдер булышам икән, моны чын күңелдән, әҗер-савап булсынга, бушка эшлим, түләү сорамыйм, шуннан канәгатьлек алам, – ди Нургаяз Ризванов. – Ызба бурасын күтәргәндә, безнең Кара Чишмә халкы бик игелекле, ярдәмчел бит, әнибез Оркыянын, рәхмәт яусын, 46 кеше (!) аш белән килде, дигәне истә. Андый хәл онытылмый бит. Дүрт ел элек кабат авылга күченеп кайткач, ике зиратта да кәрәкләрне, башка кирәк-яракны үткенләү өчен җаваплылыкны үз өстемә алдым. Динебезне хөрмәт итәм, буш вакыт булса, кулыма Коръән алам. Без – алты бертуган, шулардан бишебез, хатыным Мәрьям дә, хаҗ сәфәрендә булдык.

Хатыны – Октябрьский шәһәре кызы, аш-су остасы Мәрьям белән бер-берсен олылап гомер итә алар. Гармунчы да икән Нургаяз, ә Мәрьям – җырчы. Зур сәхнәләргә чыкмасалар да, җырлап яшиләр.

– Кара Чишмәгә кайтып яшәвебезгә үкенмим, – ди Мәрьям. – Мондагы халык булдыклы, үткен, тапкыр сүзле, уен-көлкеле, динле, ярдәмчел, юмарт.

Соңгы вакытта Нургаяз Ризванов сәламәтлеген кайгыртуга күбрәк вакыт бүлә, инде айдан артык ылыс, әрекмән, каен гөмбәсе, кычыткан, бал, кишер яфрагы һәм тагын әллә ничә төрле үләннәр кушып ясалган төнәтмә эчеп дәвалана башлаган. Бу шөгыле белән кызыксынучылар да күп икән.

...Караңгы төшкәнче өлгерәм әле, дип, оста авылдашлары алып килгән тагын бер пычкыны үткенли башлады. Үткәргеч моторының тавышы ишетелми дә, яхшы беркетелгәнгә, анда-монда шуып йөрми. Өстәмә яктырткычын да кабызып алды, күзлеген дә киеп куйды. Кабаланмады, ашыкмады. Карап торырга да рәхәт: үз көченә ышанып, яратып, пөхтә эшли. Ул шулай өйрәнгән.

Кадыйр ГОМӘРОВ

ӨСТЕЯЛ ГАЗИЗЕНЕҢ КҮРГӘННӘРЕ

Ул инде бу дөньяда юк, әмма эшләре калды, кылган гамәлләре турында хәтер калды. Сүзебез рухына дога булып барып ирешсен.

Газиз Нигъмәтҗанов 1920 елда Кызыл Юл (хәзерге Арча районы) Кече Әтнә авылында туа. Халык телендә аны Өстеял дип йөртәләр. Бу авылда юлаучылар өчен ат белән туктап, йоклап чыгу өчен «Постоялый двор» була. Авыл исеме «Өстеял» шуннан алына. Революциядән соң авыл исеме Кече Әтнә итеп үзгәртелә.

Газиз абыйны «аютабан» дип солдатка алмыйлар. Колхоз аны Балтачтагы ветфельдшерлар әзерли торган мәктәптә укыта. Ә 1939 елда Кече Әтнә авылындагы кибетне кабул итеп ала ул. Кибет белән бергә колхозда ферма мөдире дә, ветврач та, сөт-май җыючы да булып эшли. Колхоз өчен бик кирәкле кеше буларак, башта Газиз абыйны сугышка алмый торалар. Әмма фронтта хәлләр торган саен катлауланa, шулай итеп Газиз абыйга да чират җитә. Аны 1942 елның 22 июнендә Мари Элдагы даны таралган Суслонгер хәрби лагерена алып китәләр.

Газиз абыйның сөйләүләре буенча, бернинди шартлары булмаган бик кырыс лагерь ул. Анда үлүчеләр дә күп була. Монда әлеккән кешеләр тизрәк сугышка җибәреннәр иде дип тели. 3 айдан соң Газиз абыйны Воронеж юнәлешендәге фронтка алып китәләр. Ветеринар һөнәренең монда да кирәге чыга. Шушы полктагы 80 баш атны тәрбияләү, дәвалау, яраларын тәэзтү эше аңа тапшырыла. Немец самолетларыннан качып, печән богылы астында яткан чаклары да күп була. Әмма монда өч айдан артык эшләргә насыйп булмый. Эшен яралы фельдшерга тапшырып, кулына корал тотарга туры килә.

1942 елның октябрь ае аның хәтерендә аеруча уелып кала. Ул яткан окопта снаряд шартлый. Газиз абый да бик каты яралана. Әмма исән калдым дип шатланырга иртәрәк була. Әсирлеккә төшкән солдатны Германиягә алып китәләр. Ике ел да җиде айга сузылган әсирлек чорында ниләр генә күрми ул! Көнлек нормалары – бер аш чүмече кәбестә суы, пычкы чүбе кушып пешерелгән бер кисәк ипи. Ничек кыйналганнары турында әйтеп тә торасы юк.

Сугыш беткәч, Германиядән Көнбатыш Украинага көч-хәл белән җәяүләп кайта алар. Алай җиңел генә котылмый әле әсирлектә булган солдатлар. Днепропетровск шахталарында эшләтеп, шахта тузаны да сулаталар аларга. Эшкә яраксыз булып, III группа инвалид документы алгач, 1945 елның октябрь аенда гына кайтып төшә Газиз абый үзенең Кече Әтнәсенә – Өстеялга. Урман эчендәге саф һавалы туган авылында яши башлап, үзенең сәламәтлеген ныгыта ул. Сугышка киткәнче башлаган эшләренә ныклап тотына. Әмма әсирлектә булган солдатларга тыныч яшәргә ирек бирмиләр, гел тикшереп торалар. Шөкер, вакыт узгач, аңа да сугыш ветераннары белән бер сафта йөрергә насыйп була.

Мин, 1970 елда Казан кооператив техникумының бухгалтерлар әзерли торган бүлеген тәмамлап, Яңа Кенәр сельпосы бухгалтериясенә эшкә кайттым. Бу вакытта инде Газиз абый сельпоның алдынгы кибетчесе иде. Аңа сельпо идарәсе ат, арба, чана биргән. Товарны үзе ат белән ташып сата. Урман эчендә вездеход – «Урал» машиналары гына йөри ала. Мин кибеттә инвентаризациядә еш катнаша идем. Товар бик күп, хисап 3–4 көнгә сузыла. Йокларга да кала идем. Мин – сугыш чоры баласы. Сугышны киноларда карап, китаплардан укып кына беләм. Кичләрен Газиз абый сөйләгәннәрне игътибар белән тыңлыйм. Ул сөйләргә, мин тыңларга яраттым.

1970 нче елларда бу авылда 14 хуҗалык кына бар иде. Кибеткә планнар елдан-ел арттырып бирелә: ваклап сату, пай җыю, бәрәңге-йомырка, ит җыю планнары. Газиз абый йөз хуҗалыклы авыл кибетләреннән дә күбрәк сата товарны. Барлык планнарны да арттырып үтәп барды.

Ул 40 ел буена Кече Әтнә авылы кибетендә кибетче булып эшләде. 1982 елда, 62 яшендә лаеклы ялга чыкты. Бу вакытта Кече Әтнәдә 7 хуҗалык кына калган иде инде. Кибетне Минзифа апа Хәбибуллина кабул итеп алды. Тик авыл бетте. Газиз абый исә 1985 елны Яңа Кенәр авылына күченеп килде. Онытгы Фәнис, аның хатыны Фәридә тәрбиясендә булды. Ул 2008 елның 6 декабрендә 88 яшендә арабыздан мәңгелеккә китеп барды.

Габделбәр САБИРОВ,
Яңа Кенәр авылы ветераннар советы рәисе.
Арча

«ВТ» архивыннан / Фото бизәү өчен бирелде

«Балкыш»та балкыйлар

Татарстанда ветераннар арасындагы «Балкыш» республика фестиваленең сигезенчесенә әзерләнәләр. Ул өч этаптан торачак. Башта районнарда сайлап алу чыгышлары булачак. Март – апрель айларында Казан, Чаллы Кукмара, Әлмәт, Буа, Арча, Алексеевскида зона этаплары узачак. Өч гала-концерт оешгырырга ниятлиләр. Беренчесе – Җиңү көненә багышлап апрель ахрында, икенчесе май аенда Россия көненә багышлап, өченчесе октябрьдә булачак. Анысы өлкәннәр декадасына багышлап, Җиңүнең 80 еллыгына әзерлек кысасында узачак.

- 2012 елда узган беренче фестивальдә 3,5 меңгә якын катнашучы
- 2022 елда узган җиденче фестивальдә 20 меңнән артык катнашучы
- Җиде фестивальдә барлыгы 100 меңнән артык катнашучы

Хәрәкәттә – бәрәкәт

Иске Зәй яшьләр үзәгендә «Макраме» клубы активистлары – маскировка челтәрләре үрергә йөрүче апалар физкультура белән дә шөгыльләнә. Күнегүләрне туризм буенча тренер, чаңгы ярышлары һәм биатлон буенча СССРның спорт остасы Виктор Китов оештыра. Виктор Артемовичка – 82 яшь. Үзе дә тик тормый, башкаларга да үрнәк ул.

Махсус хәрби операция зонасында Ватанны саклаучы егетләргә маскировка челтәрләре үрүче бу игелекле апаларның арыган тәннәрен язарга зарядка бик тә кирәк. Күнегү ясарга да әллә кая йөрисе юк, күршедәге спортзалга гына чыгасы.

85 яшьлек Валентина Власова да биргә бик теләп йөри.

– Мин элек зарядканы өйдә ясый идем. Саф һавада йөрергә тырышам. Әлеге төркемгә күптән түгел генә кушылдым, – ди Валентина әби.

«Мәктәп» территориаль иҗтимагый үзидарәсе рәисе Светлана Долгова – бик күп игелекле эшләрдә башлап йөрүче.

– Мондый өлкәннәр булганга сөенәм. Бу хатын-кызларыбыз барысын да булдыра, махсус хәрби операциядә катнашучы егетләребезгә көчләреннән килгәнчә ярдәм итәләр, күңелләре белән дә яшь алар, башкаларны да үзләре артыннан игелекле эшләргә тарталар, – ди Светлана Ивановна.

Клара ЕРМОЛАЕВА

Кара икмәк

Әнкәй миңа кара икмәк чәйнәп,
Имезлеккә салып биргән дә,
Үзе киткән урак урырга...
Елаганмын,
ләкин чыдаганмын –
Икмәк белән була торырга.

Кара икмәк бәләкәйдән таныш,
Беләм аның кыйммәт икәнен,
Бер телеме өчен
кешеләрнең
Таңга кадәр чират көткәнен.

Кара икмәк зур мәсьәлә булган:
Йөз граммлап аны бүлгәннәр,
Кош теледәй шул граммнар өчен
Сугышканнар,
хәтта үлгәннәр...

Шул чакларны онытабыз бугай,
Әйтерсең лә күктән төшкәнбез.
Беребез дә күктән төшмәгәнбез,
Кара икмәк ашап үскәнбез.

Ул вакытлар мәңге кире кайтмас,
Без ашыйбыз хәзер калачын,
Тик калачның түмән белер өчен
Онытмаек аның карасын.

Онытмаек
җәйге чөлләрдә
Җиң сызганып кемнәр иккәнен,
Онытмаек бәрәкәтле җирнең –
Кара җирнең кара икмәген!

Әнгам АТНАБАЕВ

ТОРМЫШ ИТҮ – ДИҢГЕЗ КИЧҮ

Зәй

45 ел бергә гомер итү – бик зур бәхет. Ә шул гомерне матур итеп, сынатмыйча яши белү – үзе бер мәртәбә. Зәй районының Кабан-Бастрык авылында да матур, тату гомер кичерүче, яшьләргә үрнәк булырлык гаиләләр бихисап. Шуларның берсе – Анастасия белән Анатолий Кукиннар гаиләсе. Алар бер-берсен кечкенәдән белеп үсәләр, чөнки бер урамда яшәп, бер мәктәптә укыйлар.

Тарас һәм Зинаида Брицовлар гаиләсендә беренче бала булып кызлары туа. Аңа Анастасия дип исем кушалар. Ул кечкенәдән тырыш, уңган, сабыр, тыйнак кыз булып үсә. Мәктәпнең дә иң алдынгы, иң актив укучысы була.

Ә Анатолий Порфирьевич укытучылар гаиләсендә туа. Кабан-Бастрыкның иң оста баянчысы ул. Авылдагы бәйрәмнәр, Сабан туйлары, концерт-кичәләр, туйлар бу егеттән башка узмый. Өч ел Тын океан флотында өлкән матрос, су асты көймәсендә өлкән электрик булып хезмәт итә. Авылга матрос киеменнән кайткан егеткә байтак кызлар кызыга. Ә Анатолийның күзе авылның иң чибәр кызы Настяга төшә.

1978 елның көзендә яшь Кукиннар гаиләсе барлыкка килә. Ә керәшен авылларында туйлар җырдан башка узмый. Кодаларның бер-берсенә каршы-каршы җырлавы үзенә күрә бер опера булган заманында. Туй да беренче атнада егет ягында узса, икенче атнада кыз ягы кунаклар җыйган.

Бер ул, ике кыз тәрбияләп үстерәләр, аларны укытып, зур тормыш юлына чыгаралар. Аларның хәзер үз гаиләләре бар, оныклары да әби-бабаларын сөендереп тора.

Тормыш итү – диңгез кичү, диләр. Диңгездә тыныч һәм давыллы вакытлар булган кебек, тормыш та гел җай белән генә бармый. «Ә бер-береңә юл биреп, ихтирам итеп яшәсәң, барысын ерып чыгарга була», – ди өлкәннәр.

– Тормыш иткәндә югалтулар да булды. Сынмыйча, сыгылмыйча, нык булып яшәргә тырыштылар түти белән җизнәбез. Гомер буе тырыш хезмәт белән яшәделәр. Оныкларга шатланып, аларга бар наз-тәрбияләрен бирәләр. Уллары урынына таза, сөлек кебек ике кияү килде, – ди сеңелләре Галина Тарасовна, апасы һәм җизнәсе белән горуранып. – Без гаиләдә дүрт кыз үстек. Бүген дә балачактагы кебек, бер-беребезне күрми торсак, сагынышабыз. Әтиебез: «Бары – бергә, югы – уртак», – дип әйтергә ярата иде. Шулай бергә күңелле итеп, ярдәмләшеп, дус-тату яшибез. Анастасия түти белән Анатолий җизни янына үз әти-әниебез янына кайткан кебек кайтып йөрибез. Бу гаиләдә һәркемне ачык йөз, киң күңел белән каршы алалар. Җизни кулына гармунын алып, бергәләшеп җырлап-моңланып утырырга яратабыз.

Кайчандыр Чаллыда яшәгән гаилә, лаеклы ялга чыккач, Кабан-Бастрыкка кайтып төпләнә. Авылның, Дүртмунчаның мәдәни тормышын ямьләп яши алар. 45 ел бергә яшәү сере белән дә урталкашты Кукиннар: бер-береңне санлап, киңәшләшеп гомер итү мөһим.

Клара ЕРМОЛАЕВА

БАБАЙ ОНЫКТАН КАЛЫШМЫЙ

Буа

Адав-Толымбай авылыннан Илгиз Хәйруллин оныгы Әмир Шәрифуллин белән йөзү буенча «Буыннар бәйләнеше» республика бәйгесендә икенче урынны алганнар. Өлкән һәм яшь буынны берләштерүче әлеге ярыш Казанның Су спорты төрләре сараенда узды.

Ул ике этаптан – шәхси беренчелектән һәм эстафетадан торган. Беренчесендә Илгиз бабай да, Әмир онык та чак кына пьедесталга күтәрелми калганнар, икесе дә үз яшь категорияләрендә дүртенче урын алганнар. Ирекле стиль белән 50 метрга йөзүдә көрсәткечләре дә бер үк төрле диярлек. 36 секунд тирәсе. Ә менә эстафетада икесенә 100 метр араны 1 минут 15 секундта узып, икенче нәтиҗә күрсәткәннәр. Финишка беренче булып казанлылар килгән, өченче урынны Лениногорск командасы алган. Гомумкоманда исәбе буенча да безнекеләр икенче урында.

– Республиканың төрле районнарыннан һәм шәһәрләреннән 38 команда катнашкан бәйгедә шундый нәтиҗә күрсәтү – район өчен моңарчы күрелмәгән зур уңыш. Спортчыларыбыз Татарстанның Спорт министрлыгы һәм Россия пенсионерларының Татарстан буенча төбәк бүлекчәсенең медальләре, Мактау грамоталары, кубоклары белән бүләкләнделәр, – ди спорт ветераннары командасы җитәкчесе Вячеслав Шурбин. – Илгиз Хәйруллинның шәхси беренчелектә җиңүләре бар иде инде. 2021 елда ул йөзү буенча республика чемпионы булды. Призлы урыннар да алды.

Озак еллар туган Адав-Толымбай мәктәбендә физкультура дәресләрен укыткан Илгиз «Өченче яшь» бәйгесе кысасындагы башка спорт төрләрендә дә сынатмый. Йөзәргә ул җиде яшендә авыл күлендә өйрәнә.

– Ул вакытта бассейннар юк иде. Мәктәптә дә йөзү дәресләре кермәде. Җәй айларында балалар белән узыша идек. Тренер белән профессиональ дәрәҗәдә институтта укыганда шөгыльләндем. Белгечлегем чаңгычы булса да, ул мине, аякларын көчле дип, йөзәргә дә өндәде. Җиңүләр яуламасам да, нәтиҗәләрем яхшы иде. Организм өчен бик файдалы бу спорт төрен беркайчан да ташламадым. Мәктәптә эшләгәндә үземне формада тоту өчен җәй айларында Зәядә йөзә идем. Хәзер инде моны ел әйләнәсе эшләргә була. Районның спорт һәм туризм бүлеге тарафыннан атнага өч тапкыр бассейнга йөрү мөмкинлеге тудырылды, – ди ул.

Берничә ел элек оныгы Әмирне дә йөзәргә өйрәтә. Казан шәһәрендә яшәүче сигезенче сыйныф укучысы гимнастика белән шөгыльләнә. Ә йөзәр өчен мәктәптә бассейн бар.

– Оныгым йөзүдә дә елдан-ел остара бара. Соңгы ярышта шәхси күрсәткечен 2 секундка яхшыртты, – ди бабасы.

Алар оныгы белән Зәядә дә су коена. Авылның футбол мәйданчыгында бергәләп футбол, лапта уйныйлар. Егет ГТОның өч баскычын да алтын билгесенә тапшырган. Спорт яратучы бабай-оныкның киләчәктә пьедесталның беренче баскычына күтәрелү ихтималы бик зур.

БӘХЕТЛЕ КАРТЛЫК

Балтач

Таузар авылында гомер кичерүче тыл ветераны Мәдинә Галиуллина шушы көннәрдә үзенең 95 яшьлек олуг юбилеен каршы алды.

Күркәм юбилее уңаеннан Мәдинә апага Россия Президенты Владимир Путинның котлау открыткасы, район башлыгы Рамил Нотфуллинның Рәхмәт хаты, истәлекле бүләкләр тапшырылды. Юбилярны 95 яшьлеге белән шулай ук Карадуган авыл җирлеге башлыгы, район җитәкчелеге, социаль яклау бүлеге вәкилләре дә котладылар.

– Без гаиләдә ике бала үстек, олысы мин һәм энем Зиннур. 7 сыйныфны тәмамлауга, бераз акча юнәтү нияте беләндер инде, әнием мине мех әйберләр тегү фабрикасына эшкә алуларын сорап барды. Ябык булгач, бик шикләнделәр. Әмма мин тырышып эшләдем. Энем Зиннур өйләнде. Гаиләдә эшче көчләр дә артты. Беренче шатлыгыбыз Илфир туды. Әмма киленебез баласын, ирен ташлап чыгып китте. Шушы көннән мин Илфир энем өчен әнигә әйләндем. Икенче хатыны да гомерлек булмады Зиннурның, өч бала белән анысы да ташлап чыгып китте, – дип сөйли Мәдинә апа.

Менә шушы 4 ятим баланы җил-давыл тидерми, бар назын, күңел җылысын биреп үстерә, аякка бастыра, укыта, кеше итә Мәдинә апа.

Мәдинә апа үз гомерендә бер тапкыр да кияүгә чыкмаган, бала тапмаган. Әмма бүген ул 4 бала, 8 онык һәм 8 оныкчыкның иң кадерле кешесе булып, кадер-хөрмәттә гомер кичерә.

Кечкенә һәм ябык гәүдәле булса да, китап язарлык язмыш иясе булган Мәдинә апа белән очрашып аралашудан телсез калдым, сокландыемны аңлатырга да тиз генә сүзләр таба алмадым. Тормыш юлы турында сөйләгәндә бугазга утырган төерне чак кына йотып, авыр хезмәт баскан иңнәреннән сак кына ярап, болай да бик нечкә күңелен яралламаска тырышып, язмыш битләрен ачам.

– Кияүгә чыксаң, бу балаларны кем карар, әтиләре эштә, сабыйлар рәнҗешеннән курык, кызым, дип әйтә иде әнием. Кузсмә карап торган балаларны кызгандым, усал теләр: «Юньле булса, кияүгә чыгар иде», – дип, ярага тоз салганда да, шушы балаларны уйладым, рәнҗешләреннән курыктым, – ди Мәдинә апа күз яшьләре белән.

Илсур белән Гөлнур – Балтачта, Илнур Таузарда йорт салып чыккан, Илфир исә төп йортта Мәдинә апа белән яши.

Балалары, кияү-киленнәре, онык-оныкчыклары өчен да бик кадерле кеше Мәдинә апа. Әле үзе дә, сөбханаллаһ, камил акыл белән фикер йөртеп, үз аягында йөри, һәркемгә изге догала.

Төп йорт килене Фәгыйлә апа белән бергә тора башлаганнарына да кырык елдан арткан инде.

– Апабызны бик хөрмәт итәбез. Аңа рәхмәттән башка сүз юк. Күргән михнәт-газаплары, балалар хакына үз язмышына нокта куеп, аларны аякка бастырганы, әле дә булса төпле киңәшләре белән ярдәм итеп яшәве өчен без аңа чиксез рәхмәтле. Картлыгы сызлануларсыз, рәхәттә үтсен, дибез һәм көчебездән килгәнчә бүгенге тормышын бәхетле, куанычлы итәргә тырышабыз, – ди Фәгыйлә апа.

Гөлзидә ГАЗИЗУЛЛИНА

БИК САГЫНГАН ЧАКЛАР БУЛА

Спас

Әтисез үскәнгә микән, кечкенә чакта гел әнкәй артыннан тагылып йөрдем. Берсендә мәктәп каршындагы фонтанга ияреп бардым. Чиләкләргә су агызга гына башлаган идек, шулчак фонтан каршындагы йорттан кулына скрипка тоткан бер бабай чыгып, бакча коймасына терәп ясаган эскәмиягә килеп утырды. Ашыкмый гына озын күлмәк җиңнәрен сызганып куйды да уйнап җибәрде...

Тавышын радиодан ишеткәнем булса да, моңарчы скрипканы күргәнем юк иде әле.

– Кем бу, нишләп урамда уйный? – дип сорыйм әнкәйдән.

– Миңнебай бабаң, күңеле тулган чакларында шулай чыгып утыргалый ул...

Миңа кызык булып китте. Башына чия төсендәге түбәтәй кигән бабайның, аның кулындагы скрипкасын якыннанрак барып күрәсе килә башлады. Ни өчен дигәндә, без үскәндә, авылда гармунчылар һәм баянчылар аз түгел иде. Ә менә скрипкада уйнаучылар турында ишеткәнем булмады. Әнкәйне күндердем шул карт янына барырга. Безне күргәч, Миңнебай бабайның йөзе яктырып китте, уйнавыннан туктап, скрипкасын эскәмиягә куйды.

– И наным (әнкәйне әйбәт белгән икән ул), соңгы араларда әч поша, йөрәк сикерә башлады, дарунын да әле ни файдасын күрмим, – диде Миңнебай бабай, маңгаендагы бөрчек-бөрчек тирен кулъяулыгы белән сөртеп. – Тегендә китәргә вакыт җитә торгандыр инде, яшәмәдек түгел, яшәдек, күрәсен дә күп күрдек, бер Ходаем үзе генә белә...

Миңнебай бабай безгә яңа өйрәнгән бер көйне уйнап күрсәтте. Гап-гади татар картының шулай скрипкада өздерүенә сокланып та, хәйран калып та карап тордым. Бер көйдән икенчесенә салмак кына күчәргә кайда өйрәнгән ул, кемнән дәрес алган? Аларның нәселендә кулга мондый уен коралын тотып караган түгел, күргән кеше дә булмаган. Талант дигән нәрсә ул кешегә тумыштан килә, диләр. Талантың юк икән, теләк белән генә күп нәрсәгә ирешә алмыйсың. Димәк, Миңнебай бабай күңеленә дә җыр-моңга һәвәслек тумыштан салынган. Ни кызганыч, ул чакта мин аның кайда һәм нинди шартларда уйнарга өйрәнгәнен белә алмадым. Кечкенә идем, мине бу сорау кызыксындырмаган да булса кирәк. Инде менә шактый еллар узгач, кайбер нәрсәләргә ачыклык кертә алдым.

Миңнебай Хәмидуллин Бөек Ватан сугышында гади солдат буларак катнашкан. Совет сугышчылары белән бергә бик күп авыл-шәһәрләрне дошманнан азат иткән. Фронттагы кыюлыгы өчен дәүләтебез бүләкләренә лаек булган, берничә тапкыр җиңелчә яраланган. Сугыш юллары буйлап Европаның күп илләре аша узган, Берлинның үзенә кадәр барып җиткән. Шундагы җимерек йортларның берсендә табып алган ул кара футлярга салынган немец скрипкасын.

Хуҗалары күренмәгәч, барыбер монда ятып әрәм генә булачак, дип, уен коралын үзе белән алган.

Әлбәттә инде, командирларның рөхсәтен дә сорарга туры килгән. Әнә шулай, ерак немец иле башкаласыннан үзе белән истәлек итеп трофей алып кайткан. Шунысын да әйтергә кирәк: Миңнебай бабай сугыштан ерак илләр, ерак җирләр аша үтеп, туган якларына кайтканда ук инде көйләр чыгарырга өйрәнгән. Баштарак авылдашлары, бу Миңнебай сугыштан тагы нәрсә күтәреп кайткан инде, дип бераз гаҗәпләнеп тә куйган. Ә инде аның скрипкада уйнавын күргәч, күбесенең исе киткән. Менә бит, нимес җиреннән скрипач булып кайткан, дип шаяртучылар, хәтта әле көнләшүчеләр дә булган.

Сугыштан соң ул берничадәр вакыт колхоз председателе булып эшләп алган, башка җаваплы вазыйфаларны биләп торган. Колхозга «Сложный» дип йөртелгән агрегат кайтарылгач, шуның белән кырда көннәр буе көлтә сугып ятса, намуслы хезмәте өчен бик күп мактауга лаек булган. Колхоз эше никадәр генә арытса да, кичен кырдан кайткач, кулына скрипкасын алган. Халык җырларын, борынгы көйләрне тагын да остарак итеп уйнарга өйрәнгән. Клубта уздырыла торган бәйрәм концертларында авыл кызларын уйнап җырлаткан, биеткән. Аны хәтта мәҗлесләргә дә чакырганнар әле. Миңнебай бабай беркайчан карышып тормаган, скрипкасын култык астына кыстырып, җәлт кенә килеп җиткән. Берсендә, уен коралын киндер капчыкка салып, Казанга чыгып киткән ул. Максим Горький урамындагы 15 нче йортта урнашкан радиотапшырулар комитетына барган. Чыгышын радиога яздырып, бөтен республика халкына ишеттерәсе килгән аның. Радиокомитетта бер көйне нота буенча уйнап күрсәтергә кушканнар. Музыкаль белеме булмагач, каян белсен инде ул нотаны?! Дөрес, берничә көйне уйнап биргән, Миңнебай бабайны әле мактаганнар да. Язып алмагач, Казаннан бераз сөмсере коелып кайткан.

Аның караве алтмышынчы елларда авылга концерт белән килгән легендар Әлфия Авзалованы скрипкада уйнап җырлаткан ул. Концертларда гел уйный торган иде.

...Миңнебай бабайны мин соңгы тапкыр 5 нче класста укыганда күрдем. Озын тәнәфеска чыктык, ә ул исә йорты каршындагы бүрәнәдә утыра иде. Берничә малай янына бардык. Ул безгә томрап торган зәңгәр күзләрен тутырып карап алды да:

– И балалар, сезгә карыйм да, ачка тилмергән малай чагым күз алдына килеп баса, – диде, яшьле күзләрен сөртеп. – Ходай сезгә андый сынауларны күрсәтмәсен, бәхетле булып үсегез.

Авыл урамнарында скрипка түгел, гармун тавышлары да ишетелмәгән заманда, Миңнебай бабай кебек изге күңелле, олы җанлы, тәмле телле булып хәтергә уелып калган кешеләр торган саен сагындырып искә төшәләр.

Тәлгать ҖАМАЛЕТДИНОВ

ИГЕЛЕК БЕРЛӘШТЕРӘ

«ТАТНЕФТЬ» КОМПАНИЯСЕ ҮЗЕ ӘШЛИ ТОРГАН ТӨБӘКЛӘРДӘН КИЛГӘН ВОЛОНТЕРЛАРНЫ БЕРГӘ ҖЫЙДЫ

Игелек кылуны яшәү рәвешенә әверелдергән 112 фидакарь... «Татнефть Игелек белән» дип исемләнгән беренче форумга илнең төрле почмакларыннан әнә шулкадәр волонтер җыелды. Алар барысы да компания эшчәнлек җәелдергән төбәкләрдәге оешмаларда хезмәт куя. Төп эше белән беррәттән, игелек кылырга, әйләнә-тирәдәгеләргә кулыннан килгәнчә яхшылык эшләргә дә өлгерә алар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Мәктәп бусагасыннан башлана

«Татнефть» тарафыннан оештырылган әлеге форум волонтерлар арасында зур кызыксыну уяткан. Анда катнашырга теләк белдерүчеләрдән 200дән артык гариза кабул иткәннәр. Оештыручылар араларында «иң-иң»нәрне сайлап алган. Шул рәвешле форумга Татарстаннан тыш, Калининград, Архангельск, Ярославль, Владимир, Тольятти, Йошкар-Ола шәһәрләреннән барлыгы 112 волонтер җыелган.

«Татнефть» компаниясенең персонал белән эшләү буенча идарә начальнигы Андрей Глазков яшерми: волонтерлык эше оешмада күптәннән алып барылса да, мондый рәвештә беренче генә очрашулары.

– Җыелышып аралашу, системалы рәвештә фикер алышу бик мөһим. Бу форумга бик зур өметләр баглыйбыз. Быел безнең компаниядә яңа миссия расланды. Ул «Бергәләп без тормыш энергиясен һәм тотрыклы киләчәк өчен яңа чишелешләр булдырабыз» дип атала. Безнең компания җитештергән продукция, ул алып барган эшчәнлек кенә түгел, волонтерлар хәрәкәте дә бу максатны чынга ашыруга зур өлеш кертә, – диде Андрей Глазков.

Дөрестән дә, социаль сәясәт компания гамәлгә ашырган өстенлекле юнәлешләрнең берсе булып тора. «Татнефть» Хәйрия фондының «Татнефть» ААҖ грантлары» программасы җитәкчесе Эльмира Газизова сүзләренә караганда, компаниядә аз керемле гаиләләргә, үзенчәлекле балаларга, ветераннарга, пенсионерларга ярдәм итү, мәдәният, әдәбият, фән һәм мәгариф, спорт, сәламәтлек саклау юнәлешләрендә саллы эшләр башкарыла.

– Компаниядә спортка да зур игътибар бирелә, бик күп чаралар уздырыла. Русфондның Татарстандагы бюросы белән бергә гамәлгә кертелгән проектыбыз да бар. Аның кысасында ДЦП диагнозлы һәм аутоиммун авырулы балаларга ярдәм итәбез. Волонтерларыбыз арасында арка мие доноры булучылар да шактый, – ди Эльмира Газизова.

Компаниядә волонтерлык эшчәнлеге мәктәп бусагасыннан ук тормышка ашырыла. Әлмәттә мәктәп укучылары өчен биолабораторияләр эшли. Проект старт алган чордан алып аларга 300дән артык бала җәлеп ителгән. Аларда бер төркем укучы ел дәвамында үсемлекләр микроклонлаштыру белән шөгыльләнә. Балалар үрчеткән үсентеләрне соңрак компания хезмәткәрләре күчереп утыртып, әйләнә-тирәне яшелләндерүгә өлеш кертә.

Күңел эше

Форумда катнашкан волонтерларның кайсы белән генә аралашма, барысы да моны күңел эше дип атый. Берәүләрне төшенкелеккә бирелүдән саклый ул, икенчеләре кемгәдер яхшылык эшли алуына сөенеп туя алмый. «Татнефть» уздырган беренче форумда катнашу өчен Владимир шәһәреннән үк килгән Татьяна Каленованың, волонтерлык эшенә кереп киткәч, тормышка карашы тамырдан үзгәргән. Аларның оешмасында бүген 400ләп кеше эшли. Шуларның күбесе төп эше белән беррәттән волонтер буларак игелек кылырга да өлгерә икән.

– Без үзебезнең волонтерлар белән балалар йортларында төрле бәйрәмнәр оештырабыз. Авыру балаларга да кулдан килгәнчә ярдәм итәргә тырышабыз. Арабызда донорлар да күп. Мин үзем өченче ел рәттән кан тапшырам. Авыру балаларга да әледән-әле донорлар кирәк, – ди Татьяна Каленова.

Калининград шәһәрендә яшәүче Александр Шибков өчен волонтерлык эшчәнлеге – игелек кылу белән беррәттән, тормышта бертөрлелектән котылу чарасы да. Ул шәһәрдәге полиэтилентерефталат (термопластик) җитештерү заводында смена башлыгы булып эшли.

– Волонтерлык эшенә җиде ел элек керештем. Заводтагы кешенең ярты гомере эштә уза бит. Төрле акцияләрдә, зур чараларда волонтер булырга туры килә. Әлеге форумга фикердәшләр эзләп килдем, – ди Александр.

Шул рәвешле, «Татнефть» тарафыннан оештырылган тәүге форум «беренче коймак төерле була» дигән гыйбарәнең нәкъ киресен раслады. Ике көнлек форум дәвамында күңеле изгелектә булган күпме волонтер үзенә яңа фикердәшләр тапты, тәҗрибә уртаклашты, киләчәккә күпме максат-бурычлар билгеләнде. Оештыручылар исә әлеге форумны ел да уздырырга вәгъдә итә.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Форум барышында волонтерлар тәҗрибә уртаклашты, яңа фикердәшләр тапты.

Евгений ГАВРИЛОВ, «Татнефть» компаниясенең персонал белән эшләү буенча идарәсе корпоратив мәдәниятне һәм яшьләр сәясәтен үстерү бүлеге начальнигы:
– Бүген компания бик күп юнәлештә эшчәнлек алып бара. Әмма әлегә кадәр бу эш без теләгәнчә үк билгеле бер системага салынмаган иде. Волонтерлар форумы, иң беренче чиратта, әнә шул максат белән оештырылды. Бу юнәлештәге эшчәнлекне билгеле бер калыпка салачак документ та компаниянең иң актив волонтерлары тарафыннан эшләнсә, дөресрәк булыр. Форумда катнашучыларның яше чикләнмәгән булу да юкка түгел. Ник дигәндә, волонтерлык ул – күңел эше. Ә игелек кылу өчен ничә яшьтә булуың мөһим түгел.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың ветеринария өлкәсендәге иминлеген тәэмин итүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы «Чаллы шәһәре дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе ветеринария табибы – баш эпизоотологы **Мөхәммәтҗанов** Насыйх Шәрәфулла улы, «Алексеевск районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы – баш ветеринария табибы **Хәйбуллин** Харис Хәмит улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«Саф» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчысы (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Ибәтуллин** Рафис Мусабир улына, «Курсабаш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчысы (Татарстан Республикасының Саба районы) **Нигъмәтҗанов** Гомәр Дәүләтҗан улына, «Ак Барс» агрокомплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең авыл хуҗалыгы производствосы тракторчы-машинисты (Татарстан Республикасының Арча районы) **Шәймуллин** Гайнулла Салих улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«СОРНАЙ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш инженеры (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Гарәфетдинов** Фидаил Мәгъфур улына, «Заря» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш икътисадчысы (Татарстан Республикасының Буа районы) **Емельянова** Галина Анатольевнага, «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы җитәкчесе **Новичков** Виталий Леонидовичка **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Зеленая Роща» кулланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе **Исмәгыйлев** Радик Азат улына **«Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекциясенең Чаллы территориаль органы алкогольле продукция кертүне контрольдә тоту бүлеге башлыгы **Солощенко** Елена Борисовнага, «Татнефть-УРС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Акчарлак» кафесы пешекчесе **Субботина** Энҗе Бәгъдәнур кызына, Алексеевск районы кулланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе **Хәйбуллин** Илнур Мингаяз улына **«Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм 1941–1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүгә зур өлеш кертүе өчен Бөек Ватан сугышында катнашучы **Тимирясов** Елисей Мурза улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

Белдерү

ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОГЛАСОВАНИЯ ПРОЕКТА МЕЖЕВАНИЯ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА
Кадастровым инженером Каримуллиным Русланом Даниловичем (СНИЛС 103-594-068 40, квалификационный аттестат № 16-11-168, свидетельство СРО АКИ «Поволжье» № 0157 от 3.07.2012 года, почтовый адрес: 422701, Республика Татарстан, Высокогорский р-н, с. Высокая Гора, ул. Полковая, д. 14; тел. моб.: 89050220041, e-mail: vgora.rti@mail.ru), проводится согласование проекта межевания земельного участка, образуемого путем выдела земельных долей в счет долей в праве общей долевой собственности из земельного участка единого землепользования с кадастровым номером 16:16:000000:327, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Высокогорский муниципальный район, Ямашурминское сельское поселение (в границах ПСХК «Ямашурма»).
Заказчиками работ являются:
Ахметов Ильназ Айнурович (адрес: Россия, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Высокая Гора, ул. Дальняя, д. 60; тел.: 89673666945) и **Ахметов Алмаз Ханифович** (адрес: Россия, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Высокая Гора, ул. Полковая, д. 4Г, кв. 66; тел.: 89872268090), действующие в качестве представителей от имени участников (собственников) общедолевой собственности по нотариальной доверенности.
С проектом межевания можно ознакомиться с понедельника по пятницу с 9.00-16.00 ч. по адресу: РТ, Высокогорский р-н, с. Высокая Гора, ул. Полковая, д.14 (офис «Кадастровый центр»). Обоснованные возражения относительно местоположения границ и размера земельного участка, выделяемого в счет земельной доли, и предложения по проекту межевания земельного участка после ознакомления с ним принимаются в течение 30 дней с момента выхода газеты в печать по адресу: Республика Татарстан, с. Высокая гора, ул. Полковая, д.14 («Кадастровый центр»). При себе иметь документы, удостоверяющие личность гражданина, а также документы о правах на земельную долю.

ЯҢА ЗАКОННАРНЫ АҢЛАТАБЫЗ

Октябрь – ноябрь айларында республикада яңа законнар үз көченә керде. Үзгәрешләр, төбәк казнасы керемнәре һәм Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәре үзгәрүдән алып, шәһәр төзү эшләрен аныклау, бизнес-парклар резидентлары өчен өстәмә ярдәм чараларын кертүгә кадәр, тормышыбызның төрле өлкәләренә кагыла. Яңа законнарны тәфсилләбрәк аңлатабыз.

Илкүләм проектларга – өстәмә акча

23 октябрьдә «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 94 нче Закон үз көченә керде.

Документта быелга республика казнасы керемнәре, чыгымнары һәм бюджет дефициты берникадәр үзгәртелгән. Әйтик, бюджетның керем өлеше 56,4 миллиард сумга артып, 426,9 миллиард сумга, чыгым өлеше 40,7 миллиардтан күбрәккә артып, 456,6 миллиард сумга җиткән. Бюджет дефициты 15,7 миллиард сумга диярлек кимегән.

Республика бюджетына алынган өстәмә керемнәр хисабына илкүләм проектлар һәм федераль программаларны гамәлгә ашыру, юллар, социаль-мәдәни өлкә объектларын төзекләндерү һәм төзү дәвам итәчәк. Шулай ук бюджет оешмаларын матди-техник яктан тәэмин итүгә тәгаенләнүче акча күләме арта.

Дәүләт Советының Бюджет, салым һәм финанс комитеты рәисе Леонид ЯКУНИН:

«Катлаулы шартларда яшәвебезгә карамастан, һәр ел саен бюджетның керем өлешен арттыруга ирешеп киләбез. Республика җитәкчелеге һәм парламент тарафыннан күрелә торган чаралар нәтиҗәсе бу».

2023 елга Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең гомуми күләме **426,9 МИЛЛИАРД СУМ**, чыгымнарның гомуми күләме **456,6 МИЛЛИАРД СУМ** булыр дип фаразлана. Бюджет дефициты **15,7 миллиард сум**га кимеп, **29,7 МИЛЛИАРД СУМ** тәшкил итәчәк.

Фонд запасы арта

23 октябрьдә «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 95 нче Закон үз көченә керде.

Законда фонд бюджетының керемнәре, шулай ук чыгымнары үзгәртелгән. Керем өлеше өстәмә акчалар, шул исәптән федераль фонд бюджетыннан – 143,5 миллион сум, республика бюджетыннан 91,9 миллион сум күләмендә бюджетара трансфертлар хисабына үскән.

Быел территориаль фонд бюджеты дефициты 1,7 миллиард сум тәшкил итә. Ул финанс чыганаклары белән тулысынча тәэмин ителгән. Шул ук вакытта фондның иминият запасы 8,7 миллиард сумга җиткерелгән. Бу акча мәҗбүри медицина иминияте программаларын өстәмә финанслауга, медицина хезмәткәрләре белемен чарлауга, медицина җиһазларын сатып алу һәм төзекләндерүгә тотылачак.

2023 елга фонд бюджеты керемнәре – **70,5 МИЛЛИАРД СУМ**, чыгымнар **72,1 миллиард сум** булачак.

Муниципаль хезмәткәрләр имтихан бирми

13 ноябрьдән муниципаль хезмәткәрләр класс чины алу өчен квалификация имтиханын бирмәячәк. «Муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 99 нчы Закон үз көченә керә чөнки.

Моңа кадәр билгеле бер вакытка вазыйфа биләүчеләргә (югары төркемгә керүче вазыйфа биләүчеләрдән тыш) имтихан нәтиҗәсе буенча гына чин бирелде.

Экологик зыянны җирле хакимият юк итәчәк

2 ноябрьдә «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 106 нчы Закон гамәлгә керде.

Документ нигезендә, хәзер муниципалитетлар территориясендә әйләнә-тирә мохиткә тупланма зыян чыганакларын ачыклау, аларны юкка чыгару җирле әһәмияттәге мәсьәләгә кертелә.

Бизнес-парклар һәм авыл хуҗалыгы кооперативларына өстәмә ярдәм

2 ноябрьдә «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 102 нче Закон үз көченә керде.

Закон нигезендә, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары инфраструктурасы буларак, бизнес-паркларга һәм авыл хуҗалыгы кооперациясе өлкәсендәге компетенция үзәкләренә дә өстәмә ярдәм күрсәтеләчәк.

Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек комитеты рәисе урынбасары Ринат ГАЙЗАТУЛЛИН:

«Бизнес-парклар һәм авыл хуҗалыгы кооперациясе өлкәсендәге компетенцияләр үзәкләре өчен дә дәүләт ярдәмен күрсәтү мөмкинлеге ачыла. Биредә сүз мөлкәти, финанс, мәгълүмати, хокукый һәм консультатив ярдәм турында, шулай ук җитештерелгән товарларны (хезмәтләрне) базарга чыгаруга этәргеч бирү турында бара.

Мәдәни мирас объектларын хосусыйлаштыру шартлары үзгәрә

2 ноябрьдә «Татарстан Республикасында дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 101 нче Закон үз көченә керде.

Документта мәдәни мирас объектларын хосусыйлаштыру буенча конкурс шартларына өстәмәләр кертелгән. Бу шартларга, аерым алганда, мәдәни мирас объектларында һәм аларның территорияләрендә урам рекламасын урнаштыруга карата чикләүләр, шулай ук мондый корылма турында мәгълүматлардан торган язулар, билгеләр урнаштыруга карата таләпләр керә. Моннан тыш тиешле шартларны үтәгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мондый корылмаларны хосусыйлаштыру мөмкинлеге каралган.

Территорияләрне планлаштыру буенча документлар әзерләү тәртибе үзгәртелә

2 ноябрьдә «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 100 нче закон гамәлгә керде.

Законда территорияне планлаштыру документларын әзерләүнең моңа кадәрге тәртибе үз көчен югалткан дип танылган. Хәзер ул федераль закон нигезендә җайга салыначак. Моннан тыш Законда ике һәм аннан күбрәк торак пункт территорияләренә карата Территориаль планлаштыруның бердәм документын әзерләү мөмкинлеге билгеләнгән. Документны Министрлар Кабинеты раслаячак.

Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктураны үстерү комитеты рәисе Александр ТЫГИН:

«Үзгәрешләр ике яки аннан күбрәк җирлек, шәһәр округы өчен, яисә аларның составына керүче торак пунктлар территорияләре өчен бердәм документ әзерләү мөмкинлеген күздә тота».

Иҗтимагый күзәтчелек комиссияләре әгъзаларына түләячәкләр

2 ноябрьдә «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Законның 23 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 97 нче Закон үз көченә керде.

Законның яңалыгы шунда: җәмәгать контролен хәл итүче һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы кешеләргә ярдәм итүче иҗтимагый күзәтчелек комиссияләре әгъзаларына үз эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарын Иҗтимагый палата каплаячак.

Моңа кадәр бу чыгымнарны иҗтимагый күзәтчелек комиссияләре әгъзалыгына кандидатуралар тәкъдим иткән иҗтимагый берләшмәләр үзләре үк каплаган. Хәзер исә моның өчен акча Иҗтимагый палата бюджетына салынган.

Үз илемдә – үз телем

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстандагы төрле милләтләрнең яшәеше, гореф-гадәтләре белән таныштыра, «Бер гаилә мисалында туган телне ничек сакларга?» дигән сорауга җавап эзли.

КЫРГЫЗ

ТУГРЫЛЫК

Казан

«Казан безне бөтенләй үзгәртте», – ди алар хәзер. Ә бит 23 ел элек, акча эшлибез дә кире туган якка кайтабыз, дигән ният белән Татарстан туфрагына аяк басканнар. Әмма биредәге җылы мохит Чымынтаевларны үзенә бик тиз бөтереп алган. Шулай итеп, яшь гаилә Казанда төпләнеп үк калган. Бу юлы без бер-берсенә мәктәп елларыннан ук гашыйк булган Нургөл һәм Айбек Чымынтаевларның туган тел, гореф-гадәтләрне ничек саклавы турында язарга булдык.

Җайдаклы туй

Нургөл дә, Айбек та – Бишкәк шәһәреннән. Алар бер сыйныфта укыган. Икесе дә бер елгы, хәтта туган көннәрен бер айда бәйрәм итәләр. Яшьлектә кабынган сөю хисе бүген дә кайнарлыгын югалтмый. Чөнки ул – икесенең дә беренче мәхәббәте! Нургөл иренә – «җандаш» дип, ә Айбек аңа исеме белән дәшә.

– Кыргыз гаиләләре арасында үз сүзен өстен куярга теләгән хатыннар бар. Минем өчен ирем кушкан һәр нәрсә – закон. Айбек бик сабыр. Аның белән ике бала тәрбияләдек. Жазгөлгә – 29 яшь. Ире Нурлан белән дүрт бала үстерәләр. Улыбыз Кутманбекка – 16 яшь. Ул быел 9 нчы сыйныфтан соң Мәскәүгә киберспорт юнәлеше буенча көллияткә укырга керде, – дип таныштырды хуҗабикә гаиләсе белән.

Нургөл белән Айбекның өйләнешүе дә башкаларныкына охшамаган. Булачак каенатасы мәрхүм Мамытбек, улын өйләндергәндә, алты ат әзерләгән. Алар язылышу тантанасына атка атланып барган. Югыйсә техника заманы бит. Әмма романтик рухлы, кызык эзләп табарга яратучы Мамытбекның милли туй уздырасы килгән. Нургөл үзе дә кыю, ат өстенә менәргә курыкмаган.

– Туй көнен әле дә онытмыйм. Икебез яшәгән йорт арасы ерак түгел. Әмма шул урамны җиде сәгать буе үттек. Кыргыз халкында кавышкан көнне юлга ике кеше чыгып, аркылыга тасма сузу гадәте бар. Шулай итеп, безне адым саен туктаттылар. Атлардан төшеп, күчтәнәчләр өләштек. Җиргә кәнфитләр сиптек. Балалар сөенә-сөенә шуны җыйды. Җырладык, биедек. Безгә матур теләкләр теләделәр. Өйгә кайтып җиткәндә, сәгать кичке 11 тула иде инде. Безнең туйдан соң башка кияү-кәләшләр дә язылышырга атка атланып бара башлады, – дип елмая Айбек.

Үзгәрү

Нургөл белгечлеге буенча – география һәм экология укытучысы. Аспирантураны тәмамлагач, үзе укыган Бишкәк институтында студентларга җиде ел белем биргән. Әмма фәнни диссертация яклау чыгымнар сорый. Шуңа күрә алар Казанга барып, акча эшләп кайтырга ниятли. Бу вакытта өйләнешкән, кызлары Жазгөл туган була инде. Татарстанга килгәч, башта икесе дә базарда сату итә. Акча табыла, тик Нургөлнең генә теләге чынга ашмый. Фән хакына Казанны калдырып китәселәре килми.

Хәзерге вакытта Айбек таксида эшли. Һөнәре буенча – юрист. Әмма бу өлкәдә бер көн дә эшләмәгән. Нургөл исә Казандагы Халыклар дуслыгы йортында кыргыз балаларына кыргыз телен, мәдәниятен өйрәтә.

Менә бу урында сүзгә Айбек кушылып: «Беләсезме, Казан безне бик нык үзгәртте. Әллә яшьрәк булганга, әллә совет чорында тәрбияләнеп, динебез җитеп бетмәгәнгә, күп нәрсәгә игътибар итмәгәнбез. Дөньяви тормыш белән яшәгәнбез, күрәсең. Казанга килгәч, гореф-гадәтләр, мәдәниятебез, динебез, рухи кыйммәтләрне ныграк аңлый һәм саклый башладык. Иманыбыз ныгыды. Милли һәм дини бәйрәмнәрне дә уздырырга тырышабыз. Төп бәйрәмнәребез – Корбан, Ураза гаете һәм Нәүрүз. Үзебез дә кунакка йөрешергә яратабыз. Иң мөһиме – балаларга туган телебезне өйрәттек. Улыбыз Кутманбек монда туды. Ул кыргызча бик матур җырлый. Кечкенәдән якшәмбе мәктәбенә йөрде. Балалар мәктәптә татарча һәм русча укыса да, өйдә кыргызча сөйләште. Оныкларга да туган телебезне өйрәтергә тырышабыз», – диде.

Үз милләтен алар сабыр, тыныч халык, дип бәяли. Кыргызлар тегәргә оста. Һәр ике кешенең берсе, хәтта ир-атлар да кулларына энә тота белә икән.

Җылы бер кич

Чымынтаевлар белән очрашуны кичке якка билгеләдек. Ни өчен дигәндә, әби-бабайның эштән кайтасы бар. Бу көнне кияүләре Нурлан да кунакка кайткан иде. Әлегә аңа эше буенча башка шәһәрдә укырга туры килә. Әтиләре кайткангамы, балалар шат иде. Жанель – 3 нче, Нурель 1 нче сыйныфта укый. Аделинага – 5, Сабринага – 3 яшь.

Идәнгә милли бизәкләрдән тегелгән киез җәелгән. Гаилә әгъзалары шунда утырып, ял итәргә ярата икән. Ашый торган өстәлләре дә тәбәнәк. Урындыкка утыру гадәте юк. «Идәндә тәгәрәшәбез, анда җайлы», – диләр. Буш вакытларында шунда утырып кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматовның әсәрләрен укыйлар.

Әкият, шигырьләр өйрәнәләр. Нургөл безгә милли уен коралы – комузда уйнап күрсәтте.

– Иремнең әле бер ел укыйсы бар. Шуңа күрә балалар белән әти-әниләрдә яшәп торабыз. Бишенче сабыемны көтәм (безгә бу сөенечле хәбәрне сабыйлар ишектән керүгә үк җиткерде инде. Кайсы айда туачагын да әйттеләр. – **Автор**). Аннан Кыргызстанга кайтып китәргә җыенабыз. Күңелем Кыргызстанга тарта минем. Иремнең дә якыннары шунда бит. Җәйге каникулны әби-бабайлар янында үткәрә идек. Телне онытмаска тырыштык, – ди Жазгөл.

Нургөл белән Айбек ел саен туган ягына кайтып, туганнарының хәлен белешә. Картлык көнендә үзләренең дә Кыргызстанга кайтырга ниятләре бар. Ничек булыр? Әгәр инде Казаннан китәселәре килсә… Нургөлнең өч бертуганы да Казанда яши икән. Шуңа күрә бергә-бергә күңелле.

Якшәмбе мәктәбендә

Нургөлдән Казандагы Халыклар дуслыгы йортында оешкан кыргызларның якшәмбе мәктәбе турында да сораштык.

– Әлеге мәктәп беренче тапкыр 2002 елда ачылган. Тик кыргыз теле укытучысы туган ягына кайтып киткәч, балаларны өйрәтергә белгеч калмый. Шуннан соң мәктәп ябылып торган. 2018 елда мине эшкә чакырдылар. Базарда сату итсәм дә, каршы килмәдем. Балалар туган телен онытмасын, дип ризалаштым. Дәресләрне атнага бер мәртәбә уздырам. 6-16 яшьлек 20 бала йөри. Бары кыргыз телендә генә сөйләшәсе! Менә шундый таләп куйдым. Җәен балалар әби-бабайларына кунакка кайта. Өч ай ялның файдасы тия. Туган телдә шәбрәк сөйләшә башлыйлар, – ди Нургөл Чымынтаева.

Аның әйтүенчә, укытучы булу җиңел түгел. Һәрвакыт белемне яңартып торырга кирәк. Түгәрәктә кыргызларның мәдәниятен, тарихын өйрәнәләр. Биеп-җырлап күңел ачалар. Нургөл аларны комуз уен коралында уйнарга да өйрәтә. Башта үз акчасына алса, хәзер аны сатып алу өчен акча бүлеп биргәннәр. «Балаларга бик ошый. Хәтта әти-әниләренең дә комузда уйнарга өйрәнәсе килә», – ди Нургөл.

ВИДЕО

Гореф-гадәтләр

Җентек туй

Бала туып, 40 көннән соң, туганнар белән бергәләшеп әлеге туйны үткәрәләр.

Бишек туе

Сабыйны беренче тапкыр бишеккә салган чакта уздыралар. Кыргызлар балаларын шунда тирбәтеп үстерә. Бишекне кадерләп саклыйлар.

Беренче тапкыр тәпи киткәнен дә билгеләп үтәләр. Сабыйның аягына җеп бәйлиләр. Кем беренче күрә, аны шул кисәргә тиеш. Туганнары бүләкләр бирә.

Сөннәт туе

Сөннәткә утырту фарыз санала. Тик сөннәткә утыртуны 3, 5, 7 яшь кебек так саннарда гына башкаралар.

Милли ризык

Бишбармак

Камыр өчен 1 йомырка, 500 грамм он, 1 чәй кашыгы тоз, 200 мл су кирәк. Шулай ук 1,5 кило сарык ите, 3 баш суган, 100 грамм кишер, 1 бал кашыгы тоз, шулпа өчен 2 литр су, 10 бөртекле борыч, тәменчә тарттырылган борыч әзерләгез.

Бишбармак пешкән ит һәм камырдан ясала. Кыргызлар камырны токмач рәвешендә озын итеп кисеп пешерәләр. Ә казахларда бу форма – зур туры почмаклык яки квадратлар. Камыр өстенә ит, суган салалар. Шуны шулпа белән табынга тәкъдим итәләр.

Сәхифәне Сәрия МИФТАХОВА әзерләде.
Фото – Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5159 данә
Гомуми тираж – 13584 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 353

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+